ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
М. ХӘСӘНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ

**Р. Ф. Исламов**

# МУСА ҖӘЛИЛ

*Биобиблиографик күрсәткеч*

Казан
2026

УДК 82.512.145 (097)Д+016:82.512.145
ББК 8(Тат.)2 (092)Д+016:(Тат.)2
И 87

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе
һәм төбәкне өйрәнү институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

**Исламов Р. Ф.**
И 87 Муса Җәлил: Биобиблиографик күрсәткеч. – Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026. – 300 б. +12 б. ил.

Бу биобиблиографик күрсәткечтә Советлар Союзы Герое (1956), Ленин премиясе лауреаты (1957), шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов, 1906–1944) биографиясе, нәшер ителгән әсәрләре, тормышы һәм иҗаты турында дөнья күргән монографик хезмәтләр, гыйльми җыентыклар, якланган диссертацияләрнең авторефератлары, мәкаләләр хакында мәгълүмат тупланды. Алар хронологик яктан шагыйрь үзе яшәгән чордан алып хәзерге вакытны иңли.

Хезмәт М. Җәлилнең шәхесен һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнүчеләргә, әдәбият галимнәренә, аспирантларга, укытучыларга һәм киң гавам укучыга тәкъдим ителә.

Все права на издание, фотомеханическое воспроизведение, копирование, в том числе во фрагментах, сохраняются за издательством и автором. Любое использование материалов данного издания возможно только с письменного разрешения издательства и автора.

**ISBN 978-5-9690-1432-9**

© ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2026
© ТР ФА, 2026
© Р. Ф. Исламов, 2026

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ ҺӘМ ЯҢА БИБЛИОГРАФИЯСЕ

Советлар Союзы Герое (1956), Ленин премиясе лауреаты (1957), шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) төрле жанрларда уңышлы иҗат итеп, XX гасырның беренче яртысы татар әдәбияты, опера сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, гомумән, әдәбият һәм мәдәният тарихында тирән эз калдырган классик әдипләребезнең берсе.

Ул 1906 елның 15 (2) февралендә Оренбург губернасы, Исаево-Дедово өязе Шарлык волосте (хәзер Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында урта хәлле крестьян Мостафа Әбубәкер улы (?–1919) һәм Рәхимә Хөснетдин кызы (?–1928) Габделҗәлиловлар гаиләсендә алтынчы бала[1] булып дөньяга килгән. Башлангыч белемне туган авылындагы мәдрәсәдә мөгаллим Габдулла Усмановтан[2] ала. Бу хакта остаз шулай искә төшерә: «...Ул вакытта дүрт класс укучылары бер бүлмәдә, бер укытучы тарафыннан укытыла, I класс беренче рәттә, II класс икенче рәттә, III класс өченче рәттә, аннары IV класс 4 рәт булып утыралар иде. Унбиш көн чамасы узгач, Мусада зур үзгәрешләр сизелде: беренче класс укучысына куелган сорауларга тулы җавап бирү белән бергә, II класс укучыларына куелган сорауларга да катнаша башлады. Шулай итеп, 6 яшьлек, вакытлыча гына дип рөхсәт бирелгән Муса бик тиз вакыт эчендә беренче класс өчен бирелергә тиеш белемне үзләштерде. Минем өчен кыен яклары да булды. Хәзер инде Муса беренче класс рәтендә утырса да, күңеле белән II класс тирәсендә йөри, хәтта түздереп тә булмый башлады. Шул рәвешле мин: «Син, булмаса, Муса, бу рәткә чыгып утыр», – дип, аны II класс рәтенә утырттым»[3].

---

[1] Чыганаклардан күренгәнчә, әүвәл туган дүрт бала кечкенә вакытта ук вафат була. Аннары абыйсы Ибраһим, сеңелләре Зәйнәп, Гайшә (вафат була), Хәдичә, энеләре Закир, Зәки (икесе дә ачлык елларында вафат була).

[2] *Габдулла Усманов* – Габдулла Габдрахман улы Усманов 1888 елның 16 апрелендә Оренбург губернасы (хәзер Оренбург өлкәсе) Тукай авылында туган. 1907 дә «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлагач, үзенең авылында мөгаллим булып эшли. 1910 да Мостафа авылына күчеп килә. Бирәдә 1914 тә Галимә Ногман кызы (1896–1977) белән гаилә кора һәм алар Тукайга кайтып китәләр. 1932–1933 тә алар янә Мостафа авылында укыта, Габдулла мәктәп мөдире була. Башкортстанның Чакмагыш район Советы Башкарма комитеты рәисе булып эшләгән бертуган энесе Камил Усмановның (1902–?) тәкъдиме белән 1934 тә Рәҗәп авылына килеп урнашалар. Ә 1935 тә Яңа Карьяуды авылында төпләнәләр һәм гомерләрен балалар укытуга багышлыйлар. Тырыш хезмәтләре өчен икесе дә «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакяр хезмәт өчен» медальләре, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 1949 елда Габдулла Ленин орденына лаек була.

Г. Г. Усманов 1960 елның 16 сентябрендә вафат була, Яңа Карьяуды зиратында дәфен кылына.

[3] Усманов Г. Мәктәптә / Г. Усманов // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 6.37

Тормыш шартлары авыраеп китү сәбәпле, гаилә 1913 елда Оренбургка күченеп китәргә мәҗбүр була һәм әүвәл кардәшләре Хаммат Сәйфетдиновларда (?–?)[4] сыену урыны таба[5], аннары «Хөсәения»[6] мәдрәсәсенең ишек алдындагы подвалда яши башлый. Муса белем алуын шул уку йортында дәвам иттерә (1914–1915, 1915–1916, 1917–1918). Мәдрәсәдә үзенең сыйныфында зур булмаган дивар газетасы чыгара. Абыйсы Ибраһим Җәлилов (1901–1979) бу хакта үзенең истәлегендә шулай яза: «Класс күләмендә чыга торган бу газета Муса редакторлыгында, аның мәкалә һәм шигырьләре белән тулы була иде»[7]. Ул бик теләп «Урал» номерларының аскы катында урнашкан «Белек»[8] китапханәсенә йөри, китаплар укый. Шул вакытларның хатирәсе буларак, 1917 елда сабакташы Кадыйр Мостаев[9] белән төшкән фото да сакланып калган[10].

1918 елның язында Габделҗәлиловлар янә авылга кайта. Укуын дәвам иттерү өчен Ибраһим гына Оренбургта кала. Шул елларда авылда укытучы Гали Игъдисанов (?–?) җитәкчелегендә беренче тапкыр «Анам кабере» исемле шигырь буенча инсценировка уйнала. Муса анда ятим малай ролен башкара.

Әдәбият галиме Гази Кашшаф (1907–1975) бу әсәрнең шагыйрьләр Бәхтияр Мирзановның (1892–1941) «Анам кабере янында» яки Зариф Бәширинең (1888–1962) «Анасы кабере янында бер кыз» исемле шигырьләре булу ихтималын билгеләп, шулай ди: «Яшь шагыйрь Муса Җәлил үзеннән өлкән шагыйрьләрдән ятимлек, газаплану мотивларын алса да, ул шигырьнең эчтәлегенә социаль төс бирергә омтыла»[11].

Җәй вакытында ул абыйсы янына шәһәргә килә. Ә көзен башлангыч мәктәптә укытучы булып эшләгән шагыйрь Төхфәт Ченәкәй (1893–1959) белән таныша һәм дуслашып китәләр. Бу аның дөньяга карашына һәм иҗат фикерләвенә бәрәкәтле йогынты ясый. Киләчәктә иң якын булачак дустының шәхси китапханәсендәге борынгы татар шагыйрьләренең һәм Шәрекъ классикларының әсәрләрен укый, шигырь төзелешенең серләренә төшенә.

---

[4] Х. Сәйфетдиновның хатыны Ракыя – М. Җәлилнең энисе Рәхимәнең бертуган сеңелесе.

[5] Шәймиев Ф. Сәйфетдиновлар һәм Җәлил / Ф. Шәймиев, Ф. Искәндәров // Яңа Вакыт (Оренбург). – 2001. – 9 февр.

[6] *«Хөсәения»* – Оренбургта бертуган сәүдәгәрләр, иганәчеләр Әхмәт (1837–1906), Мәхмүт (1839–1910), Габделгани (1839–1902) Гали уллары Хөсәеновлар тарафыннан 1889 елда ачылган мәдрәсә. 1919 да ябыла.

[7] Җәлилов И. Яшьлек еллары (Истә калганнардан) / И. Җәлилов // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 6.

[8] *«Белек»* – 1928 елдан Хөсәен Ямашев исемен йөртә; хәзерге вакытта Оренбург шәһәре китапханә-мәгълүмат системасының филиалы.

[9] *Кадыйр Мостаев* – Кадыйр Мөхәммәт улы Мостаев (1904–1974), хезмәткәр, граждан-нар һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, 1942 елда авыр яраланып, демобилизацияләнә. Ташкентта төрле хуҗалык оешмаларында һәм җитәкче урыннарда эшли.

[10] Зәбиров И. Бер рәсемнең тарихы / И. Зәбиров // Яшь ленинчы. – 1976. – 13 нояб.

[11] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк / Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. – Б. 35.

1919 елда җәйге ял вакытында Муса авылның башлангыч мәктәп балалары белән спектакль куюны оештыра. Бу хакта аның сеңелесе Зәйнәп Җәлилова (?–?) шулай искә ала: «Спектакль көткәннән артык уңышлы үтте. Безне бик мактадылар... Спектакльдән соң без кечкенә генә концерт бирдек: хор белән җырладык. Муса мандолинада уйнады. Зөһрә Мәүлүтова белән икәү парлап җырладык»[12].

Шул елның сентябрь аенда әтисе Мостафа абзый вафат була. Гаиләгә ярдәм итү максаты белән Ибраһим авылга кайтып китә һәм мәктәптә укытучы булып эшли башлый. Кышын Муса да Мостафага кайта. «Кызыл йолдыз» исемле балалар түгәрәге оештыра (соңрак «Кызыл чәчәк» дип үзгәртелә). Аның өч кешелек бюросына ул үзе, Зәкия Сәйфуллина (?–?), Бари Вахитов (?–?) сайлана. Түгәрәкнең уставы языла, кулъязма журнал чыгарыла, яшь һәвәскәрләр пьесалар, концертлар куя. «Артист»ларыбыз күбәеп китте. Театрны ике атнага бер куеп тора башладык. Хәзер инде барлык пьесаларның да исеме хәтердә калмаган, тик «Варенье», «Ураза тотканда», «Бәйрәм көн», «Хәерче бала» исемле пьесаларны гына хәтерлим», – дип яза З. Җәлилова[13].

Якташы, «Хөсәения» мәдрәсәсендә сабакташы, соңыннан күренекле башкорт язучысы булган Сәгыйть Агиш (1904–1973) үзенең истәлегендә Мусаның «Варенье» дигән пьесасы әйтелгән уку йортында, ә «Усал» дип аталганы шәһәр сәхнәсендә куелганлыгы турында мәгълүмат китерә[14].

Иҗат белән Муса 1915 елларда ук шөгыльләнә башлый. Бу уңайдан гыйбрәтле бер хәлне искә төшереп үтү урынлы булыр. Бертуган сеңелесе Хәдичә Җәлилова (1918–2000) истәлегеннән күренгәнчә, алар Оренбургта яшәгән вакытта кардәш тиешле бер кеше килә. Киткән вакытта галошының зурлыгыннан зарлана. Мостафа абзый аны-моны уйлап тормастан, тәрәзә төбендә яткан дәфтәрдән бер битне ертып ала да, аны йомарлап, галош башына тыгып куя. Ә ул кәгазьдә Мусаның шигыре язылган була...[15].

Туганнан туган сеңелесе Мәрьям Сәйфетдинова (?–?) язганча, 1915 елның башында Муса әнисе белән аларга бәби туена килгәч, башкаларга сиздермичә генә үзенең Мостафа авылына һәм язгы кояшка багышлап язган ике шигырен укый[16].

1917 елда язган бер шигырен «Вакыт»[17] газетасына тәкъдим итә, ләкин ул басылмый кала. Үзе язганча, 1916–1917 елларга караган шигырьләре сакланмаган.

---

[12] Җәлилова З. Мусаның балачагы / З. Җәлилова // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 20.

[13] Җәлилова З. Күрс. чыг. – Б. 20–21.

[14] Агиш С. Шагыйрь турында кайбер истәлекләр / С. Агиш // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 40–41.

[15] Җәлилова Х. Безнең Муса / Х. Җәлилова // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 23.

[16] Сәйфетдинова М. Яшь вакытлар / М. Сәйфетдинова // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 31.

[17] *«Вакыт»* – алтын приискалары хуҗалары, танылган иганәчеләр һәм җәмәгать эшлеклеләре бертуган Мөхәммәтшакир (1857–1912) һәм Мөхәммәтзакир (Дәрдемәнд) (1859–1921) Мөхәммәтсадыйк уллары Рәмиевләр наширлегендә һәм журналист, язучы җәмәгать

Алга таба иҗат иткән «Ятим бала» (1918, сакланып калган беренче шигыре), «Хакыйкать» (1918), «Тартыш», «Тилгән», «Ил халкына», «Ил тәбриге», «Ил корбаннары» (дүртесе дә 1919) шигырьләре билгеле[18]. Ә «Бәхет» дип аталган шигыре «Кечкенә Җәлил» тәхәллүсе белән беренче мәртәбә «Кызыл йолдыз»[19] газетасының 1919 елгы 65 нче санында дөнья күрә. Әдәбият галиме Г. Кашшаф бу шигырьдә Габдулла Тукай (1886–1913) һәм Демьян Бедный (1883–1945) иҗатларының[20] йогынтысын тоемларга мөмкин дигән фикер белдерә[21]. Бу басмада аның тагын унлап шигыре басыла.

1920 елның җәендә Мостафа авылында Оренбург губернасындагы татар укытучыларының конференциясе була. Анда Муса «Балалар түгәрәге»нең эшләре турында доклад сөйли. Алга таба Түгәрәк пионер оешмаларына нигез була. Авылның партия оешмасы йөкләмәсе буенча комсомол ячейкасы оештырыла. Ул анда кабул ителә һәм җитәкчесе була. Ячейканың үзәген дә әнә шул Түгәрәкнең актив әгъзалары тәшкил итә.

Озакламый Мусаны волостьның комсомол комитетына әгъза итеп сайлыйлар һәм 1921 елның җәендә Оренбургка китә. Анда танышлары ярдәмендә губерна совет-партия мәктәбенә урнаша. Аның белән бергә укыган Закир Рахманкулов (?–?)[22] ул вакытларны шулай искә ала: «Курсантлар ЧОН[23] батальонында сугышчылар булып исәпләнәләр иде. Еш кына аудиториягә винтовкалар һәм билгә буылган патронташлар белән килә идек»[24]. Ләкин Муса, алты ай укыганан соң бик нык авырып, бер елга якын хастаханәдә дәвалана.

---

эшлеклесе Фатыйх (Мөхәммәтфатыйх) Гыйльман улы Кәрими (1870–1937) мөхәррирлегендә Оренбургта 1906–1918 елларда нәшер ителгән татарча көндәлек сәяси һәм әдәби газета. Барлыгы 2308 саны дөнья күрә.

[18] Бәдигый Х. И уян, ил... / Х. Бәдигый // Мәдәни җомга. – 2014. – 14 февр.

[19] *«Кызыл йолдыз»* – кызылармиячеләр газетасы, Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе сәяси бүлеге һәм РКП(б)ның Каспий аръягы өлкә комитеты органы. 1920 елның 19 апреленнән 9 сентябренә кадәр Сызрань шәһәренә, Сорочинск станциясендә (Оренбург өлкәсе), Бозаулык, Оренбург һәм Полторацк (хәзер Ашхабад) шәһәрләрендә татар телендә нәшер ителә. 1920 дә төрек һәм үзбәк телләрендә бастырыла.

[20] Аерым алганда биредә Г. Тукайның «Күңел йолдызы» (1909) һәм Д. Бедныйның «Маяк» (1918) исемле шигырьләре турында бара – *Р. И.*

[21] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк... – Б. 37–39.

[22] *Закир Рахманкулов* – Закир Хөсәен улы Рахманкулов (1902–?), икътисад фәннәре кандидаты, доцент, соңгы елларда Уфада авыл хуҗалыгы институтында укыта. М. Җәлил рабфакны тәмамлап, Оренбургка кайткач, алар янә очрашалар һәм 1926 елның сентябрендә Саттар Ижбулдин (?–?) – өч сабакташ фотога төшәләр: Рахманкулов З. Корыч шулай чыныкты: Үлемсезлек таңында / З. Рахманкулов // Соц. Татарстан. – 1966. – 13 февр.

С. Ишбулдин комсомол эшенә Урта Азиягә җибәрелә, озак еллар Үзбәкстанда төрле оешмаларда җаваплы эшләрдә эшли.

[23] *ЧОН* – Часть особого назначения.

[24] Рахманкулов З. Күрс. хезм.

Терелеп чыкканан соң, Татар халык мәгарифе институтына (русча кыскартылмасы – ТИНО)[25] кабул ителә. Бу techinститутта чыга торган «Истикъбал йолдызы» («Киләчәк йолдызы») исемле кульязма журналда актив языша. Сабакташы, хезмәттәше, Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны Фатих Исхаков (1906–1993)[26] язганча, ул вакытта Мусаның кульязма ике җыентыгы була. Аларның берсендә «Елан һәм керпеләр», «Кәрәкә һәм кысла» дигән мәсәлләр, «Сарик[27] малай», «Балык тотканда», «Туган авылыма» исемле шигырьләр, «Ятим бала» пьесасы булганлыгы искә алына[28]. Бер үк вакытта шәһәрдәге балалар йортында тәрбияләнүчеләр белән эшләргә дә вакыт таба. Институтта бергә укыган сабакташы Гайшә Мөхәммәдиева (?–?)[29] М. Җәлилне шулай искә ала: «Муса бик шаян, кызыклы сүзләр белән кешене үзенә җәлеп итә, көлдерә, үзе дә уен сүзне күтәрә, бер дә үпкәләми, ачулана белми иде. Укучылар шул елларда шактый ачлык күрделәр. Ач көе уку кыен, әлбәттә. Муса безнең күңелләрне күтәреп, укырга яңа көч, дәрт кертеп китә иде... Гомумән, Муса, бик киң холыклы, бераү белән дә бәйләнеп йөрми, ачуланмый иде. Һәрвакыт яхшы киңәш бирә, авыр көннәрдә кулыннан килгән ярдәмне һичбер кызганмый иде»[30]. Ә Пәрвәз Әбдерәшитова (?–?) исә аның иҗат белән шөгыльләнүен тасвирлый: «Муса бик тиз – ике көн эчендә пьеса язып өлгертә… Муса пьесалар гына түгел, шигырьләр дә күп яза һәм аларны укырга ярата иде. Аңа тыңлаучы кирәк булган күрәсең. Безнең бүлмәгә кереп, ул теләсәң-теләмәсәң, үз шигырьләрен укырга керешә иде. Мин бүгенгә җитәр инде дисәм дә, ул тагын берне, тагын берне генә дип укый торгач, шактый күп укый иде»[31].

[25] «Хөсәения» мәдрәсәсе каршында 1916 елда губерна земствосы тарафыннан педагогия курслары оештырыла, ә ике елдан соң татар укытучылар семинариясе ачыла. 1919 ның 15 октябрендә Көнчыгыш халык мәгарифе институты, 1921 дә Татар халык мәгарифе институты итеп үзгәртелә. 1921–24 тә аның директоры булып педагог Нургали Сибгатулла улы Надиев (1882–1940) эшли. 1940 ның ахырында аның бинасы Оренбург авыл хуҗалыгы институты карамагына тапшырыла.

[26] Аның турында: Хисамиев И. Их, гомер агышлары... / И. Хисамиев // Татарстан яшьләре. – 1989. – 14 март.

[27] *Сарик* – угры.

[28] Исхаков Ф. Орденлы миллионнар сафында. Беренче очрашу / Ф. Исхаков // Үлемсезлек таңында: Муса Җәлил турында истәлекләр / Ред. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – Б. 16–18.

[29] *Гайшә Мөхәммәдиева* – Гайшә Камал кызы Мөхәммәдиева (?–?), табибә, Оренбург губернасы, шул ук өяз, Имәнгол авылында мөгаллим гаиләсендә туган. Әүвәл белемне үзенең авылы мәктәбендә ала. Аннары Оренбург Татар халык мәгарифе институтында укый (1921 елдан). 1925 тә Казанга барып медицина техникумына укырга керә. Аны тәмамлагач, туган якларына кайтып эшли. Бөек Ватан сугышы вакытында медицина өлкән лейтенанты дәрәҗәсендә Оренбургтагы госпитальләрнең берсендә хезмәт итә. 1961 дә лаеклы ялга чыга. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, табиблар тәкъдиме белән, Үзбәкстанның Наманган шәһәренә күченеп китә һәм гомеренең ахырына кадәр шунда яши.

[30] Мөхәммәдиева Г. ТИНОда / Г. Мөхәммәдиева // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 49.

[31] Әбдерәшитова П. Гади, елгыр егет / П. Әбдерәшитова // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 54–55.

Шул вакыттагы иҗаты хакында М. Җәлил үзе шулай яза: «1922 елда, яңадан шигырь белән кызыксынып, бик күп шигырьләр яздым. Бу елларда мин борынгы Иран шагыйрьләреннән Гомәр Хәйям[32], Сәгъди[33], Хафизлар[34] һәм татар шагыйрьләреннән Дәрдмәндне[35] бик укый идем. Минем шигырьләрем дә алар тәэсирендә романтик рухта язылдылар. Бу чорда язылган «Янчы, дөнья», «Әсирлектә», «Үлем алдыннан», «Башактан тәхет», «Теләктәшлек», «Киңәш» һәм башкалар романтизм стилендә язылганнар»[36].

Үзенең белемен арттыру нияте белән Казанга укырга җибәрүләрен сорап, 1922 елның 5 октябрендә Халык мәгарифенең Оренбург бүлегенә гариза яза[37]. Ул вакытта инструктор булып эшләгән Гариф Фәхретдинов[38] башта гаризаны кире кагулары, хезмәткәрләр белән киңәшкәннән соң, уңай фикергә килүләре хакында сөйли[39]. Шул ук елның ноябрендә Казанга килә. Бу турыда үзенең автобиографиясендә шулай яза: «Кайбер иптәшләрнең киңәше белән 1922 елның көзендә Казанга килдем. Мин Казанны әле белми идем. Анда танышларым да юк иде. Ләкин үземнең шигырь көчемә нык ышану мине Казанга канатландырды... Бик күп юл җәфалары күрә-күрә, Казанга килеп җиттем. Анда язучылар белән көрештем. Укырга инде вакыт соң иде. Мин «Татарстан»[40] газетасы редакциясенә күчереп язучы булып кердем»[41]. Бу вазифаны ул 1923 елның көзенә кадәр башкара. Г. Мөхәммәдиевага 1923 елның 11 июнендә юллаган хатында үзенең хәлләре турында шулай яза: «Үземнең хәлләр начар түгел. Жалуния яхшы. Үзем идарәдә сотрудник (язучы) булып хисапланам. Газетада, журналларда мәкаләләр язып байтак гонорар да эшлим. Шушы көннәрдә

---

[32] *Гомәр Хәйям* – Гыяседдин Әбелфәтех ибне Ибраһим (1048–1122), фарсы һәм таҗик шагыйре, математик һәм философ.

[33] *Сәгъди* – Мөслихеддин Әбу Мөхәммәд Габдуллаһ ибне Мөшрифәддин (1203–1210 арасы – 1292), фарсы шагыйре һәм фикер иясе.

[34] *Хафиз* – Шәмседдин Мөхәммәд (як. 1325–1389 яки 1390), фарсы шагыйре.

[35] *Дәрдмәнд* – Закир (Мөхәммәтзакир) Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1859–1921), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, алтын приискалары хуҗасы, иганәче.

[36] Җәлил М. Тормыш юлым // Җәлил М. Әсәрләр: дүрт т-да / Томны төз., иск. хәзер. Г. Кашшаф; фәнни ред. Н. Юзиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 3 т.: Шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр, биографик материаллар, хатлар. – Б. 450.

[37] Гаризаның факсимилесен кара: Мостафин Ф. Эзләнүләр дәвам итә / Ф. Мостафин // Соц. Татарстан. – 1972. – 10 март.

[38] *Гариф Фәхретдинов* – Гариф Галиулла улы Фәхретдинов (1897–1976), педагог.

[39] Мустафин Ф. И. Муса Джалиль – педагог: Вопросы коммунистического воспитания в наследии татарского поэта-героя / Под ред. Р. А. Низамова / Ф. И. Мустафин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 15.

[40] *«Татарстан»* – 1918 елның 12 мартыннан чыга башлаган иҗтимагый-сәяси көндәлек татар телендәге газета. 1918–1920 дә «Эш», 1920–1922 дә «Татарстан хәбәрләре», 1922–1924 тә «Татарстан», 1924–1951 дә «Кызыл Татарстан», 1951–1960 та «Совет Татарстаны», 1960–1992 дә «Социалистик Татарстан», 1992 нең февраленнән «Ватаным Татарстан» исемнәре белән нәшер ителә; редакция әүвәл Тукай, 1923 нең 22 гыйнварынннан Большая Проломная (хәзер Бауман ур., 9) урамында урнашкан.

[41] Җәлил М. Тормыш юлым... – Б. 450.

балалар әдәбиятында эшләргә туры килеп тора. «Балалар мәҗмугасы»на булышчы мөхәррирлек тә итәм. Минем язганнарым анда аерым дикъкать белән керә баралар. Тиздән үземнең «Мәҗмугаи асар»ымның беренче төбен бастырмакчы булам.

Танылган язучылар, матбугатка актив язышучылар белән аралашып эшләү М. Җәлилнең эшчәнлегенә уңай йогынты ясый. Шуңа күрә, «Ул үзенең хәбәрләренә башта «Хәбәрче-укучы М.», «Хәбәрче Муса», «Муса», «М. Җәлил» дип куя... 1923 елда гына аның «Татарстан» газетасы битләрендә төрле-төрле темаларга язылган, кызыклы проблемаларны күтәргән иллегә якын материал чыга»[42].

1923 елда Фәтхи Бурнаш (1898–1942) «Көрәш җырлары»[43] дип аталган җыентык төзеп бастыра. Анда М. Җәлилнең «Кызыл көч», «Башактан тәхет», «Ерак илләрдән», «Парча», «Үлем тырнагыннан...», «Нигә бирдең җиләк...» дигән һәм тагын исемсез ике шигыре урын алган.

Аннары Казан Көнчыгыш педагогия институты каршындагы төрки-татар эшчеләр факультетының техник бүлегенә укырга керә. Шул вакытларда аның ике пәрдәле, өч күренешле көлкеле «Кала малае» исемле пьеса[44], «Күк йөзендә»[45], «Ачып куйдым бүген мин гөл зарымны», «Сукачы угылы»[46] дигән шигырь язуы, «Бибкәй кыз» (4 актта музыкаль драма), «Һабил-Кабил» (3 актта опера) әсәрләрен сәхнәдә куюю өчен татар драма түгәрәге артисты Зөлкарнәй Байкин[47] белән шартнамә төзүе дә мәгълүм. Әйтергә кирәк, «Бибкәй кыз» музыкаль драмасы 1925 елның 11 гыйнварында Татар театрында Фәттах Латыйпов[48] һәм Зәйнәп Хөсәенова (?–?) бенефисында уйнала. МОПРның[49] Татарстан өлкә комитеты нәшриятында «Барабыз»[50] исемле беренче җыентыгы басыла.

1923 елның ахырында Казанга А. В. Луначарский (1875–1933) килә. Ул рабфак студентлары белән дә очраша. М. Җәлилнең сабакташы Әкрам Сафин (?–?) истәлегеннән күренгәнчә, бу очрашудан соң Татрабфакның тормыш шартлары шактый ях-

---

[42] Хамматов Ш. Муса Җәлил – эшче-хәбәрче, журналист / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1981. – 28 июль.

[43] Көрәш җырлары (Соңгы шагыйрьләрдән җыентык) / Төз. Ф. Бурнаш. – Казан: Татар. дәүләт. нәшр., 1923. – 239 б.

[44] Әхмитов М. Танышу кичәсе / М. Әхмитов // Кызыл яшьләр. – 1924. – 8 янв.; Хамматов Ш. Муса Җәлил – драматург / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1988. – 28 апр.

[45] Бәдигый Х. Күрс. хезм.

[46] Хәмиди Л. Бергә булган чаклар / Л. Хәмиди // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 57.

[47] *Зөлкарнәй Байкин* – Зөлкарнәй Мөхәммәтҗан улы Байкин (1888–1936), драма актёры, режиссёр.

[48] *Фәттах Латыйпов* – Фәттах Мәннаф улы Латыйпов (1884–1966), актёр, беренче профессиональ татар җырчыларыннан (лирик тенор), музыка әсәрләре авторы.

[49] *МОПР* – Международная организация помощи борцам революции (Революция өчен көрәшүчеләргә халыкара ярдәм оешмасы).

[50] Җәлил М. Барабыз (Революция көрәшчеләре өчен ясалган кичәләргә материаллар) / М. Җәлил. – Казан: МЛПРның Татарстан өлкә комитеты, 1925. – 39 б.

шыртыла. Шушы үзгәрешләрдән соң М. Җәлил «Луначарский килде» дигән шигырь яза һәм дивар газетасында бастыра[51].

Шул чордагы иҗатын үзе шулай шәрехли: «Рабфак еллары минем иҗатымда борылыш тудырдылар. 1924 елда мин бөтенләй икенче рухтагы шигырьләр яза башладым. Революцион көрәш, эшчеләр тормышы, завод-фабрикалар, яңа авыл темалары миндә реаль төстә чагылдылар. Мәсәлән, бу чор шигырьләреннән «Иске Себер җыры», «Авыру комсомолец», «Эш карты», «Заводлар кочагында», «Эш баласы», «Газета», «Съезддан», «Төнге марш», һ. б. күрсәтергә мөмкин»[52]. «Татарстан» газетасында «Матбагачылар ячейкасында», «Татар эшче факультетларында», «Балалар әдәбиятына ярдәмгә» дигән мәкаләләре дөнья күрә. Ул «Октябрь» әдәби күмәгенә әгъза булып язылa, «Кызыл яшьләр»[53], «Клич юного коммунара»[54], «За Ильичем» газеталарының һәм «Октябрь яшьләре»[55] журналының хәбәрчесе, «Яшь ленинчы»[56] газетасының редколлегия әгъзасы була.

Бу чорда «Татарстан», «Кызыл байрак»[57] «Крестьян газеты»[58] газеталарында, «Безнең юл»[59], «Кызыл Шәрекъ яшьләре»[60], «Яшь эшче»[61] журналларында аның байтак шигырьләре басыла.

---

[51] Сафин Ә. Муса – Татарабфак студенты / Ә. Сафин // Казан утлары. – 1969. – № 11. – Б. 166.

[52] Җәлил М. Тормыш юлым... – Б. 451.

[53] *«Кызыл яшьләр»* – 1920 елның 22 гыйнварыннан Казанда татар телендә нәшер ителүче яшьләр газетасы. Башта Россия коммунистик яшьләр союзы Казан губерна комитетының мөселман бюросы газетасы, аннары ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты органы буларак басыла, 1920–1938 елларда – «Кызыл яшьләр», 1938–1956 да – «Яшь сталинчы», 1956 дан соң «Татарстан яшьләре» исемендә чыга. 1942 нең 24 мартында чыгудан туктый, 1949 нең 21 августында кабат нәшер ителә башлый.

[54] *«Клич юного коммунара»* – 1919 елның 25 октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителүче атналык республика яшьләре газетасы. Исеме 1919–1925 тә – «Клич юного коммунара», 1930–1933 тә – «На штурм», 1938–1941, 1949–1991 дә – «Комсомолец Татарии», 1991–1992 дә – «Комсомолец Татарстана», 1992 дән – «Молодежь Татарстана».

[55] *«Октябрь яшьләре»* – «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналының дәвамы буларак 1924–1925 елларда нәшер ителә. 1925–1930 да *«Авыл яшьләре»*, 1930 дан «Колхоз яшьләре» исеме белән басыла. 1933 тә «Атака» журналы белән берләштерелә.

[56] *«Яшь ленинчы»* – 1924 елның 10 октябреннән Казанда татар телендә атнага ике чыга, 2002 дән – атналык газета. 1991 дә исеме «Сабантуй» дип үзгәртелә, 2014 тә журнал булып чыга башлый.

[57] *«Кызыл байрак»* – иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Мөселман социалистлары комитеты органы.

[58] *«Крестьян газеты»* – ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССРның Җир эшләре халык комиссариаты басмасы. 1924 елның 25 апреленнән 1935 елның 30 августына кадәр Казанда чыга. 1930 елның 25 февраленә кадәр «Колхоз газетасы» исеме белән нәшер ителә.

[59] *«Безнең юл»* – Казанда 1922 дән 1930 га кадәр шул исемдә нәшер ителгән айлык әдәбинәфис, иҗтимагый-сәяси журнал, 1930–1932 дә Татар пролетар язучылар ассоциациясе органы «Атака» һәм ТАССР Мәгариф халык комиссариаты һәм Татар совет язучылары җәм-

1924 елның июль аенда каникул вакытында туган якларына кайтканда, Казаннан Самарага баручы «Раскольников» пароходында якташы, табиблар тәкъдиме буенча шәһәрдән китәргә мәҗбүр булган драматург Мирхәйдәр Фәйзи (1891–1928) белән очрашалар. Ул «Юлга чыкканда ук: «Кулым ике, йөрәгем саусыз, багажым дүрт... Ничек кайтып җитәрмен инде», – дип борчыла. Пароходта Муса Җәлилне очраткач, ул бик шатлана»[62].

Шунысын да әйтеп үтү урынлы булыр: Казанда ул бик күп язучылар һәм шагыйрьләр белән турыдан-туры аралаша, тыгыз хезмәттәшлек итә. Шуңа күрә дә 1925 елның февраль аенда танылган язучы Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) «Пролетариат әдәбияты турында» (Мәскәү, 1924) исемле китабын автограф белән аңа бүләк итүе очраклы хәл түгел.

Рабфакта уку тәмамлану һәм аның чыгарылыш кичәсен Гайшә Байчурова (?–?) шулай тасвирлый: «1925 елны без рабфакны тәмамладык. Бу – беренче чыгарылыш иде. Шушы вакыйгага багышлап июнь аенда Татар академия театры бинасында зур тантаналы кичә ясалды. Кичәнең художество бүлеге өчен Муса махсус инсценировка язды. Аның бөтен эчтәлеге тулысынча исемдә калмаган. Ләкин сюжеты рабфакның ике еллык тормышын, ягъни туып-үсү тарихын гәүдәләндерә иде. Анда ялгыз һәм күмәк җырлар да, коллектив сөйләүләр дә, биюләр һәм физкультура чыгышлары да бар иде. Бертуктамый музыка уйнап торды. Бөтен рольләрне һәм номерларны, Татар коммунистик университетыннан кайбер иптәшләрнең катнашы белән, үзебезнең рабфак укучылары башкарды»[63].

Бу вакытларның хатирәсе буларак, бергә укыган сабакташы Нәгыймә Насыйрова[64] белән 1923 елның 23 декабрендә төшкән фотосы сакланып калган[65]. Ул аңа «Ил

---

гыяте органы «Яңалиф», 1933 елдан 1965 елга кадәр «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исемендә.

[60] *«Кызыл Шәрекъ яшьләре»* – РКСМның Татарстан өлкә комитеты органы, яшьләр журналы. Беренче саны 1922 елның гыйнварында дөнья күрә. 1924 кә кадәр нәшер ителә.

[61] *«Яшь эшче»* – айлык иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби, рәсемле журнал. ВЛКСМ Үзәк комитеты каршындагы Татар-башкорт бюросы органы. 1922 елның апрелендә Шәрекъ яшьләре үзәк бюросы тарафыннан оештырыла, атналык «Яшь эшче» газетасы җирлегендә барлыкка килә. 1922 нең декабреннән 1928 нең мартына кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 64 саны чыга.

[62] Хамматов Ш. Казан арты – Балтач яклары: Юл язмалары / Ш. Хамматов, Г. Шәмсетдинов // Соц. Татарстан. – 1982. – 16 окт.

[63] Байчурова Г. Ул яхшы иптәш тә иде... / Г. Байчурова // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 72.

[64] *Нәгыймә Насыйрова* – Нәгыймә Миңнур кызы Насыйрова (1905–1979), инженер-икътисадчы, Беренче Мәскәү университетының юридик факультетын М. Җәлил белән бер чорда тәмамлый. Күп еллар Аралашу юллары министрлыгында эшли.

[65] Шамова Ә. Бер рәсемнең тарихы / Ә. Шамова // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 128–129.

чәчәгенә (Эшче кызның альбомына)» дигән шигырь дә багышлый[66], шигырьләр дәфтәрен дә биргән була. Ләкин анысы турында оныта. 1928 елның 15 февралендә Мәскәүдән язган хатында шул хакта искә төшереп, гозерен җиткерә: «Мин [19]25 нче елны ук бер шигырьләр дәфтәремне югалткан идем. Өч ел буена эзләп кайгырып янып таба алмый һәм кайдалыгын белә алмый аптырадым. Бүген Шамов[67] миңа шул турыда сөйләде. Һәм ул дәфтәрнең синдә булганлыгын әйтте. Син, зинһар, шуны үзең белән алып кил әле. Онытма, алып кил! Ышанам»[68].

Рабфакны тәмамлаганнан соң М. Җәлилгә үзе теләгән югары уку йортына укырга керү мөмкинлеге ачыла. Ләкин ул туган якларына кайтырга карар кыла. 1925 елның 24 апрелендә Г. Мөхәммәдиевага язган хатында үзенең шундый планнары белән уртаклаша: «Ләкин мин ВУЗга кергәнгә кадәр бер ел (ике җәй, бер кыш) ял итәргә исәплим. Ул ялым минем бөтенләе белән үзебезнең авылда үтәр. Бәлки, шул ук вакытта сезнең тирә-як белән дә аралашырга туры килер. Ни булса да инде, кыскасы: бу кайту — озак вакытка кайту, Оренбург-Мостафам белән соңгы элемтәм, соңгы сабуллашуым булыр. Шул вакыт эчендә мин бөтен элекке дусларым, элекке күргән-белгәннәрем белән тагын бер кат нык кына аралаша-кайнаша алам. Ә аннан соң инде, беләк сызганып югары белем (ВУЗ) диңгезенә кереп киткәч, тәмам тулы бер кеше булып чыкмый торып, ул якларга тиз генә әйләнергә туры килмәс»[69].

1925 елның 3 июнендә ул Казан Көнчыгыш педагогия институты каршындагы төрки-татар эшчеләр факультетының техник бүлеген тәмамлау турында 13 санлы шәһадәтнамә алганнан соң, шундый уй-ниятләр белән Мостафага кайта һәм авыл дөньясына кереп китә. Тиздән аны комсомол ячейкасы секретаре итеп сайлыйлар.

Озакламый М. Җәлилне Оренбург губерна комитеты үзенә чакырып ала һәм Орск шәһәренә азчылык милләт комсомол өяз комитеты инструкторы итеп эшкә җибәрә. Бу вазифада ул 1925 елның 2 сентябреннән 1926 елның 1 августына кадәр була. Өязнең төрле волостьларында (мәсәлән, Домбравск, Н. Покровск, Кумак-Кыргыз һ. б.) комсомол эшенең торышын тикшерә, киңәшмәләр үткәрүне оештыра, анда чыгышлар ясый. Оренбург яшь пионерлары өяз бюросының I пленумында (1926 ел, 20 октябрь), Каргалы авылында укытучылар конференциясендә (1927 ел, 25–29 май) катнаша.

Язган хисапларыннан күренгәнчә, «Җәлил булган фактларны күрсәтү белән генә чикләнеп калмаган. Җирле шартлар белән җентекләп танышканнан соң, ул комсомол оешмасы секретаре һәм бюро членнары белән бик озак сөйләшеп утырган, аларга план төзергә ярдәм иткән, бюро утырышы һәм комсомол җыелышы үткәр-

---

[66] Җәлил М. Ил чәчәгенә (Эшче кызның альбомына) // Җәлил М. Әсәрләр: дүрт т-да / Томны төз., иск. хәзер. Г. Кашшаф; фәнни ред. Н. Юзиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 1 т.: Шигырьләр. 1918–1941. – Б. 98.

[67] *Шамов* – Афзал Шиһабетдин улы Шамов (1901–1990), язучы, җәмәгать эшлеклесе; 1925–1930 елларда Беренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультеты студенты. Нәгыймә – А. Шамовның хатыны Гадилә Насыйрова-Шамованың (1902–1982) бертуган сеңелесе.

[68] Муса Җәлил – документларда / Төз.: Р. Исламов. – Казан: Җыен, 2021. – Б. 284.

[69] Җәлил М. Тормыш юлым... – Б. 465.

гән, анда политик темага доклад белән чыккан, стена газетасы чыгаруда катнашкан, драма коллективына ярдәм иткән»[70].

Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Мәсәлән, «аны Орск шәһәрендәге Вахитов исемендәге үзәк татар клубы каршындагы үсмерләр секциясе җитәкчесе һәм татар пропагандистлар коллективы җитәкчесе итеп билгелиләр»[71].

1926 елның 12 ноябрендә ВЛКСМның Оренбург азчылык милләт өяз комитетына инструктор итеп билгеләнә.

Бу вакытларда ул ВКП(б) сафларына керү турында уйлый һәм партиягә кабул итүләрен сорап, ВКП(б)ның Орск кулланучылар җәмгыяте каршындагы 3 нче ячейкага гариза яза (1926 ел, 6 июнь). 1926 елның 25 июнендә ВКП(б) әгъзалыгына кандидат итеп кабул ителә (таныклык № 5234).

Ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының Татар-Башкорт бюросы һәм ВЛКСМның Башкортстан өлкә комитеты басма органы булган «Яшь юксыл» газетасында «Кулсызлар», «Ленинчыдан», «Төнге марш» дигән шигырьләре, «Казах волостенда», «Комсомол эшендә ирекле группалар методы», «Бөтендөнья балалар атнасы», «Без – партия һәм комсомол чакырган фронтта» исемле һәм башка публицистик язмалары дөнья күрә. 1928 елда, газетаның биш еллык юбилее уңае белән, «Яшь юксылга» дигән тәбрик шигыре бастырыла[72].

1927 елның 21 апрелендә Шәрекънең милли азчылык ВЛКСМы хезмәткәрләренең берләштерелгән Бөтенсоюз киңәшмәсенә Оренбург комсомол оешмасыннан делегат итеп сайлана һәм ВЛКСМ ҮКның Татар-Башкорт секциясенә кертелә. Шул ук елның 24 апрелендә Оренбургта үткәрелгән татар-казакъ коммунистларының 3 нче губерна киңәшмәсендә катнаша, соңыннан күмәк фотосурәткә төшәләр[73].

Югары уку йортына керү ниятен белдереп үзен эштән азат итүләрен сорап, шул елның 3 июнендә ВЛКСМның Оренбург өяз комитеты бюросына гариза яза.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретариаты үзенең 1927 елгы 5 август утырышының карары белән (52 нче беркетмә) аны Мәскәүгә ВЛКСМ Үзәк Комитеты органы булган «Кечкенә иптәшләр»[74] исемле балалар өчен татар телендә чыга торган журналда эшләү өчен ВЛКСМ Үзәк Комитеты карамагына чакыртып ала. Шул нигездә ул 1927–1928 елларда журналының җаваплы мөхәррире вазифасын үти. Басма Казанга күчерелгәч, аның инициативасы белән «Октябрь баласы»[75] дигән журнал оештыры-

---

[70] Мостафин Р. Утта чыныккан яшьлек / Р. Мостафин // Соц. Татарстан. – 1976. – 12 февр.

[71] Мостафин Р. Утта чыныккан яшьлек...

[72] Гимадиев Ү. «Яшь юксыл»да / Ү. Гимадиев // Кызыл таң. – 1966. – 15 февр.

[73] Хәмидуллин Л. Ерак еллар хатирәсе / Л. Хәмидуллин // Татарстан хәб. – 1993. – 13 февр.

[74] *«Кечкенә иптәшләр»* – балалар өчен айлык рәсемле журнал, ВЛКСМ ҮК каршындагы Татар-Башкорт бүлеге органы. СССР халыклары үзәк нәшрияты тарафыннан 1924 елның мартыннан 1928 нең апреленә кадәр Мәскүдә нәшер ителә. Барлыгы 47 саны дөнья күрә. 1927 нең сентябреннән М. Җәлил аның мөхәррире була.

[75] *«Октябрь баласы»* – балалар өчен айлык рәсемле журнал, ВЛКСМ ҮК һәм Мәгариф халык комиссариаты органы. «Кечкенә иптәшләр» журналының дәвамчысы. 1929 елның ав-

ла һәм җаваплы мөхәррире (1929–1933), бер үк вакытта ВЛКСМ Үзәк Комитетының Татар-Башкорт бюросы әгъзасы (1927–1930) була.

М. Җәлил «Кечкенә иптәшләр» журналының сыйфатын яхшырту һәм эчтәлеген баету юнәлешендә күп көч куя. Моның өчен тәҗрибәле язучыларны, галимнәрне хезмәттәшлек итәргә чакыра. 1927 елның 2 сентябрендә язучы, әдәбият галиме Гали Рәхимгә (1892–1943) язган хатында шундый юллар бар: «Журналны бөтен балалар массасына җавап бирерлек ясар өчен аңа бөтен педагогия, укытучы курслары, балалар әдәбиятының аталары якын килергә тиеш. Менә шул нигездә, Гали абый, сезне дә үсеп килгән алма балаларның киләчәге намына шушы бөек хезмәткә чакырам. Журналның ышанычлы таянычлары, якын булышчылары һәм акыл әйтүчесе, төзәтүчесе сафыннан үзегезне 1 рәттә санап, вакытыгыз сыйдырганча ярдәм итсәгез икән»[76].

Журналга язышучы яшь талантларга да зур игътибар юнәлтә. Аларга үзенең төпле киңәшләрен бирә, иҗат үсешенә рухландырып тора. Мәсәлән, булачак язучы Кәшфи Басыйровның (1906–1943) «Дүрт һәм бер» исемле хикәясен анализлап язылган хатында (1927 ел, 21 ноябрь) аның кайбер җитешсез якларын күрсәтә. Шул ук вакытта ул болай ди: «Язып тор. Язганда да менә шул тормыш эчендә кайнау юлыңны үзгәртмә! Ул бик әйбәт. Хикәяңнең беренче бүлемен кертү турында фикереңне яз. Исемен әйт. Кертербез»[77].

Матхан Атнагол[78] исемле яшь хәбәрчегә язган хатын (1927 ел, 9 декабрь) мактау сүзләре белән башлый: «Моңарчы безгә матур гына шигырьләр җибәреп торуыгызга шатлыгыбызны белдерәбез. Моннан соң да үзегезне «Кечкенә иптәшләр»нең даими, якын булышчыларыннан санап, шулай эш сезонына һәм вакыт агышына бәйләп язмаларыңны җибәреп тор. Синең бигрәк тә уңышлы язмаларыңнан итеп «Без дә күчтек», «Кышкы иртәне»не[79] санарга кирәк»[80]. Икенче хатында (1929 ел, 16 декабрь) шулай ди: «Беренче кар» журналыбызның ноябрь номерында – беренче

---

густыннан 1932 нең декабренә кадәр Мәскәүдә нәшер ителә. Барлыгы 41 саны дөнья күрә. 16 июльдән мөхәррире М. Җәлил.

[76] Муса Җәлил – документларда... – Б. 278.

[77] Муса Җәлил – документларда... – Б. 281.

[78] *Матхан Атнагол* – Матхан Атнаголов-Буйский (?–1956), Башкортстанның Яңавыл районы Кисәккаен дигән авылда яшәп, әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, матбугатка хәбәрләр язган. «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларында шигырьләре басыла. Мәсәлән, Атнаголов М. Кәримнең бакчасы / М. Атнаголов // Кечкенә иптәшләр. – 1925. – № 6–7 (14–15). – Б. 5; *Аныкы ук*. Без дә күчтек / М. Атнагол // Кечкенә иптәшләр. – 1926. – № 8 (40). – Б. 12; *Анкы ук*. [Ике куплетлы исемсез шигырь] / M. Atnaƣul / Oktəbr balasь. – 1930. – № 1. – B. 12. һ. б. (Моңа кадәрге тикшеренүләрдә аның тулы исеме, нишләптер, китерелми. Аның «Буйский» тәхәллүсенә килгәндә исә, шул яклардагы Бүә (русча Буй) елгасына нисбәтле алынган).

[79] *«Кышкы иртә»* – дөресе: «Кышкы иртән»: Атнагол М. Кышкы иртән / М. Атнагол // Кечкенә иптәшләр. – 1926. – № 11 (43). – Б. 5.

[80] Муса Җәлил – документларда... – Б. 282.

биткә кергән иде[81]. Укыгансыңдыр... «Коммуна балалары»н бөтен көе ашыгыч арада кертеп булмаса да, аерым куплетларын бик уңышлы гына урыннарга эре хәрефләр белән кертербез дип торабыз... Син шигырьне оста һәм образлы язасың. Тик сиңа теманы конкретлаштырырга кирәк»[82].

Яшь хәбәрче Гали Фазлыевка[83] урында эшне оештыру юнәлешендә шундый киңәшләрен бирә: «Эшне алып барырга уңай булсын өчен үз тирәңә актив җыйна. Шул тирәдә «Октябрь баласы» дуслары (бала хәбәрчеләр) түгәрәген төзеп җибәр. Ул түгәрәккә без эш кулланмалары язып җибәрербез. Түгәрәк журналга хәбәрчеләр җыярга, аларның әйберләрен тикшереп карап журналга җибәрергә, журналны тикшереп, критика ясап барырга һәм аны редакциягә җибәрергә, журналны таратырга тиеш»[84].

Күренә ки, М. Җәлил һәр яшь хәбәрчеләр белән шулай дустанә мөнәсәбәттә аралашып торган, журналны чыгаруда балаларның үзләрен турыдан-туры катнаштырырга, шул рәвешле басманы чын мәгънәсендә аларныкы итәргә тырышкан.

Әйтергә кирәк, бу юнәлештә редакциянең башка хезмәткәрләре дә читтә калмаган. Мәсәлән, Балтач районы Пыжмара авылындагы Сөләйман Мөлеков[85] исемле укучыга «Пионер каләме»[86] журналында эшләүче Абдулла Алиш[87] шундый хат яза: «Хөрмәтле иптәш Мөлеков! Сезнең шигырьләрегезне укыдым. Сездә язу куәсе бар. Шигырьләрегезнең байтагы миңа ошады. Берсен «Пионер каләме» журналының киләсе номерында басарбыз. Шулай да әле сездә кимчелекләр дә юк түгел. Күбрәк укырга, әдәбият теориясен бик нык өйрәнергә кирәк»[88].

М. Җәлил 1927 елда Беренче Мәскәү дәүләт университетының әдәбият һәм сәнгать факультетына укырга керә. Бу югары уку йортында төрле милләт вәкилләре

---

[81] *«Беренче кар» журналыбызның ноябрь номерында – беренче биткә кергән иде* – Atnaƣol M. Brence qar / M. Atnaƣol // Yktəber balasь. – 1929. – № 4. – B. 1.

[82] Муса Җәлил – документларда... – Б. 289.

[83] *Гали Фазлыев* – Гали Фазлыев (?–?), 1950 елларда Башкортстан АССРы Туймазы райкомы инструкторы була.

[84] Муса Җәлил – документларда... – Б. 287.

[85] *Сөләйман Мөлеков* – Сөләйман Мифтах улы Мөлеков (1920–1941), яшь шагыйрь, Бөек Ватан сугышында һәлак була.

[86] *«Пионер каләме»* – «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларының дәвамы: 1933–1941 елларда «Пионер каләме» (1941–1950 дә чыкмый), 1951 дән – «Пионер», 1957 дән – «Ялкын». Журналны оештыручы – М. Җәлил.

[87] *Абдулла Алиш* – Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев (1908–1944), шагыйрь, балалар язучысы, антифашист, 1908 елның 15 сентябрендә хәзерге Татарстан Респбликасы Спас районы Көек авылында туган. Җидееллык мәктәпне, техникумны тәмамлый. Казанда «Пионер каләме» журналы редакциясендә җаваплы сәркятип булып эшли (1933–1941). Бөек Ватан сугышында 1941 нең сентябрь аенда әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. 1944 елның 25 августында Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 12 минутта) җәзалап үтерелә. Район үзәгендә каһарманның музее бар, туган авылында бюсты куела.

[88] Шакир С. Ул җырлар калдырды / С. Шакир // Яшь ленинчы. – 1967. – 26 авг.

белем ала. Мәсәлән, мари язучысы һәм галиме Яныш Ялкайн[89] белән алар җылы мөнәсәбәттә, гаилә дуслары булалар. Я. Ялкайн үзенең «Ола»[90] («Кала») дигән автобиографик повестенда М. Җәлилне татар егете Хәсән Рәшитов образында гәүдәләндерә[91].

Шул вакытларда ВЛКСМ Үзәк Комитеты карары белән РСФСР Халык мәгарифе комитетының азчылык милләтләр Советына Үзәк бюро вәкиле итеп сайлана.

ВКП(б)га әгъза итеп алуны үтенеп, 1928 елның 15 маенда әлеге югары уку йортының партия ячейкасына гариза яза. 1929 елның 20 апрелендә ВКП(б) сафларына кабул ителә.

Шул елда аның «Иптәшкә»[92] дигән шигырьләр җыентыгы һәм «Авылда пионер эшләре»[93] исемле хезмәте басылып чыга. Рабфак буенча сабакташы, шул вакытларда Мәскәү университетында укыган Г. Байчурова үзенең истәлегендә М. Җәлил «Иптәшкә» китабын автограф белән 1929 елның 12 апрелендә бүләк итүен яза[94].

1930 елның май аенда Мәскәүдә ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар телендә «Ударниклар»[95] дигән айлык журнал нәшер ителә башлый. М. Җәлил аның редколлегия әгъзасы була.

Шул ук елның июль аенда Башкортстан АССРның Чишмә районы Кара Якуп авылында ял итә. Анда танылган җырчы Зәйтүнә Илбаева (1906–1983) һәм аның гаиләсе (ире – журналист Гомәр Илбаев (?–1933), кызы Земфира) белән таныша, дуслашып китә. Күмәк фотога да төшәләр[96]. Зәйтүнә ханым Мәскәү консерваториясенә укырга кергәч, алар тагын очраша. Бу хакта ул шулай яза: «1933 ел. Мин Мәскәү консерваториясенә укырга киттем. Шунда, татар студиясе студентлары арасында, Муса Җәлил белән тагын да очрашырга туры килде. Бу танышлык тора-бара иптәшләрчә якын дуслыкка әйләнде. Чөнки безнең фикерләребездә, тормышка карашыбызда бик күп уртак яклар бар иде... Аның белән теләгән темага: хәзерге заман яшьләре нинди булырга, кызлар үз-үзләрен ничек тотарга, егетләр белән кызлар арасындагы мөнәсәбәт, хәзерге гаилә ничек булырга тиеш дигән темаларга киңәшләшеп, бәхәсләшеп була иде»[97]. Соңыннан хат алышып торалар[98].

---

[89] *Яныш Ялкайн* – Яныш Ялкаевич Ялкайн (1906–1938), мари язучысы, тәрҗемәче, фольклорчы, этнограф, библиограф; шәхес культы чоры корбаны, үлгәннән соң аклана.

[90] Йалкайн Й. Ола: Повэсть / Й. Йалкайн. – М.: «Сылнэ литэратур» Кугужаныш савыкташ, 1936. – 213 с.

[91] Арсланов Л. Күңелләр береккәндә / Л. Арсланов // Соц. Татарстан. – 1986. – 14 февр.

[92] Җәлил М. Иптәшкә (Теләктәшкә). Шигырьләр төргәге / М. Җәлил. – М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1929. – 76 б.

[93] Avьlda pijanir eşlərə / Jazucьsь: M. Çəlil. – M.: SSSR Xalьqlarьnьŋ yzək nəşr.,1929. – 67 b.

[94] Байчурова Г. Ул яхшы иптәш тә иде... – Б. 73.

[95] *«Ударниклар»* – эшче яшьләр өчен айлык рәсемле, иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал, «Яшь эшче» журналы дәвамчысы. 1930 елның маеннан 1932 елның декабренә кадәр чыга. Барлыгы 32 саны дөнья күрә.

[96] Мостафин Р. Җәлилнең билгесез рәсеме / Р. Мостафин // Казан утлары. – 2001. – № 2. – Б. 185–186; Шәрипов М. Дим кызына / М. Шәрипов // Кызыл таң. – 1986. – 15 февр.

[97] Илбаева З. Аның хаты / З. Илбаева // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 75.

Алар 1936 елның июль аенда Башкортстанның «Йоматау» санаториясендә тагын бергә ял итә. Журналист Хәлил Маннан[99] үзенең истәлегендә кайбер ял итүчеләрнең исемнәрен китерә: «Алар арасында: ул заманда халык бик яратып тыңлый торган, Мәскәү консерваториясеннән укудан кайткан яшь җырчы Зәйтүнә Илбаева, Башкортстанның танылган артистларыннан Әмин ага Зөбәеров[100], Галимҗан Карамышев[101], Хаҗи Бохарский[102], Таңсылу Рәшитова[103], шагыйрь Хәй Мөхәммәдъяров[104] һәм башка язучылар, җаваплы эшчеләр бар иде... Без Мусаны көн саен гына түгел, көненә берничә мәртәбә күрә идек. Ул беркемгә карата да үзен эре тотмый, теләсә кем белән ихластан сөйләшә, шаяра»[105]. М. Җәлил З. Илбаевага «Дим кызына» дигән махсус шигырь дә багышлый һәм ул «(Зәйтүнәгә)» исем белән басылып чыга[106].

Анда М. Җәлилнең якташы, булачак композитор Җәүдәт Фәйзи (1910–1970) дә ял итә. Бу хакта ул шулай яза: «1930 елны без, Муса белән алдан сөйләшү буенча, Башкортстанның Чишмә районы Кара Якуб авылындагы ял йортында очраштык. Айга якын бергә тордык. Урманда йөрдек, волейбол уйнадык, кичләрен танцыларга йөрдек. Безнең яраткан эшебез, кичләрен үз тирәбезгә яшьләрне җыеп әдәбият турында сөйләшү, бергәләшеп җырлау иде»[107]. Кызганыч ки, ул үзенең истәлегендә башкаларның исемнәрен күрсәтми. Алда телгә алынган күмәк фотоны М. Җәлил дүртьюллык шигырь язып, шул елның 17 октябрендә Җ. Фәйзигә бүләк иткән.

М. Җәлил 1931 елның 19 июнендә Мәскәү дәүләт университетының әдәбият һәм сәнгать факультетының редакция-публицистика бүлеген тәмамлый.

---

[98] Әхмәт Р. Бер мәхәббәт тарихы: Муса Җәлилнең Зәйтүнә Илбаевага язган хатлары / Р. Әхмәт // Татарстан. – 1994. – 3–4. – Б. 148–151.

[99] *Хәлил Маннан* – Хәлил Маннанов (?–?), журналист, 1930 елларда «Коммунист» газетасының актив хәбәрчесе, 1935 елларда Башкортстан АССРы Кандыра МТСында политбүлек газетасы мөхәррире.

[100] *Әмин Зөбәеров* – Әмин (Габдулла) Фәхретдин улы Зөбәеров (1891–1963), актёр, РСФСРның (1949) һәм Башкортстан АССРның (1935) халык артисты.

[101] *Галимҗан Карамышев* – Галимҗан Харис улы Карамышев (1903–1977), актёр, РСФСРның (1955) һәм Башкортстан АССРның (1940) халык артисты.

[102] *Хаҗи Бохарский* – Хаҗиәхмәт Гыйрфанетдин улы Галимов (Бохарский) (1899–1974), актёр, режиссёр, Башкортстан АССРның халык артисты (1944).

[103] *Таңсылу Рәшитова* – Сәгыйдә (Таңсылу) Фәрри кызы Рәшитова (1905–1988), актриса, Башкортстан АССРның халык артисты (1940).

[104] *Хәй Мөхәммәдъяров* – Хәй Габдрәфыйк улы Мөхәммәдъяров (1911–1941), шагыйрь, Бөек Ватан сугышында һәлак була.

[105] Маннан Х. Дим буенда / Х. Маннан // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 77–78 .

[106] Җәлил М. (Зәйтүнәгә) // Җәлил М. Әсәрләр: дүрт т-да / Томны төз., иск. хәзер. Г. Кашшаф; фәнни ред. Н. Юзиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 1 т.: Шигырьләр. 1918–1941. – Б. 305–306.

[107] Фәйзи Җ. Онытылмас хәтирәләр / Җ. Фәйзи // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 86.

Шул елның җәендә аның Башкортстандагы Туймазы шәһәрендә булуы да билгеле. Башкорт язучысы Баязит Бикбай (1909–1968) язганча, районда «Ленин юлы» исемле газета оештырып, икенче ел эшләп йөргәндә, Дим Баязит[108] чакыруы буенча, Тымытык районының[109] бер авылында ял итүче М. Җәлил кунакка килә[110].

1932 елның җәендә «Коммунист» һәм Урал өлкәсендә[111] татар телендә нәшер ителә торган «Социализм юлы» газеталары редакцияләре эшче-крестьян хәбәрчеләрнең слётын үткәрә. Анда М. Җәлил дә катнаша һәм «Матбугатның хәзерге бурычлары» дигән доклад белән чыгыш ясый[112]. Шул ук вакытта ул Надеждинск (хәзер Серов) шәһәрендә металлургия заводының домна һәм мартен цехларында була, эшчеләр белән аралаша, «Коммунист» газетасы өчен материаллар туплый. Шунда мартен миче янында берничә фотога да төшә[113].

Кәгазь җитмәү сәбәпле, «Октябрь баласы» журналы 1933 елда ябыла һәм М. Җәлил СССР Үзәк Башкарма Комитеты органы булган татар үзәк «Коммунист» газетасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли башлый. Чуашстанның халык шагыйре Яков Ухсай (1911–1986) Мәскәүдә М. Җәлил белән газетада эшләгән вакытларын шулай искә төшерә: «Мәскәүдә чыга торган «Коммунист» газетасы (татар телендә) белән «Коммунар»[114] газетасы (чуаш телендә) редакцияләре Никольский урамының 10 номерлы йортында бер үк коридорда булып, хәтта аларның икесен аерып торган ишек тә юк иде. Мин, ике халык (татар халкы белән чуаш халкы) вәкилләренең менә шушы якын күршелеге аркасында, Муса Җәлилне көн саен күрә идем, аның «Коммунист» газетасында еш кына чыгып торган шигырьләрен даими рәвештә укып бара идем. Ара-тирә ул минем, мин аның шигырьләрен тәрҗемә итешә идек»[115].

Шул ук елның сентябрендә Казанда үткәрелгән II Бөтентатар колхозчы ударниклар съездында «Коммунист» газетасының үз хәбәрчесе сыйфатында катнаша һәм редакциягә телеграф аша хәбәрләр тапшырып тора. Аннан соң 1 ноябрьгә кадәр Ту-

---

108 *Дим Баязит* – Баязит Фәтхелислам улы Баянов (1909–1945), язучы.

109 *Тымытык районы* – ТАССРда, 1930 елның 10 августында оештырыла. 1931 елның 20 октябрендә, район үзәген Азнакай авылына күчерү сәбәпле, Азнакай районы итеп үзгәртелә.

110 Бикбай Б. Күңел аша яктылык / Б. Бикбай // Кызыл таң. – 1966. – 15 февр.

111 *Урал өлкәсе* – 1934 елдан Свердловск өлкәсе.

112 Валеева Н. Муса Джалиль на Урале / Н. Валеева // Ленин. путь. – 1980. – 15 февр.

113 Зәбиров И. Бер рәсемнең тарихы / И. Зәбиров // Соц. Татарстан. – 1976. – 8 февр.; Хәбибуллин Ф. Муса Җәлил фатыйхасы белән / Ф. Хәбибуллин // Кызыл таң. – 2019. – 15 февр.

114 *«Коммунар»* – чуаш телендәге үзәк газета, башта ВКП(б) Үзәк Комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге каршындагы Чуаш секциясе органы, 1932 елдан – СССР Үзәк Башкарма Комитеты Милләтләр Советы органы. 1926 ның 10 сентябреннән 1930 ның 29 ноябренә кадәр «Ĕçлекенсен сасси» үзәк чуаш журналы урынына нәшер ителә. 1930 ның 7 июненнән 1932 нең 8 гыйнварына кадәр «Чăваш хресченĕ» исеме белән басыла. 1932 нең 14 гыйнварыннан «Центральная чувашская рабочая газета» дип атала.

115 Ухсай Я. Идел улы / Я. Ухсай // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 81–82 .

лада Косогор металлургия заводында командировкада булып, андагы хәлләр турында язып чыга.

1934 елгы язгы чәчү кампаниясе уңае белән газетаның күчмә редакциясе мөхәррире сыйфатында Түбән Идел краеның Дергач районына җибәрелә. Андагы эше шул елның 11 маенда Хәсән Туфанга (1900–1981) язган хатында ачык чагылыш таба: «23/III та килгән идем. Тиздән 2 ай тула. Шуннан бирле газет чыгарып ятам. Газет көндәлек. Эш ифрат тыгыз. Бик аз йоклыйм. Көн-төн чабам. Район бик авыр өзеклектә. Колхозлар егылган. Бик күп көч түгәргә туры килә. Эш авыр һәм катлаулы. Ләкин миндә әз генә дә дәрт сүнгәне юк. Мин бу килүемнән бик-бик разый. Әле тагын уборкага да шулай күчмә редакция белән җибәрүләрен сорар идем. Бик бирелеп, колхозларның йөрәгенә кереп эшлим»[116]. Бер үк вакытта районда даими татар газетасы чыгару шартларын булдыра. Мәсьәләне Сталинградка[117] барып хәл итәсе генә кала.

Ул 11 июльдә Дергачтан юлга кузгала. Әмма Саратов белән ике арадагы юлда аның барлык әйберләрен (шул исәптән документларын да) урлыйлар, өстәвенә бик нык авырып китә. Шул сәбәпле Сталинградка кермичә, Әстерханга китәргә мәҗбүр була.

Әстерханда М. Җәлилне бик җылы каршы алалар. 28 июльдә зурлап аның иҗат кичәсен үткәрәләр[118]. Август башында Түбән Идел крае Нариман районының Килинчи авылы Калинин исемендәге колхозның ВКП(б) ячейкасы гомуми җыелышында бригадаларда партия-масса эшләре һәм авыл хуҗалыкларының бурычлары турында доклад белән чыгыш ясый.

Әмма авыр матди як мәсьәләсе хәл ителми. Шул вакыт Т. Ченәкәй аңа ярдәм кулы суза, ягъни почта аша берникадәр күләмдә акча җибәрә.

Шул ук елның 1 августыннан 8 октябренә кадәр Татарстанның Әлки районындагы «Чирмешән» совхозында урып-җыю кампаниясе вакытында була. Ул Чуаш Кичүе авылында Камалия Гыйниятуллина-Нуретдиноваларда (?–?) квартирда яши.

1934 елда Башкортстанның Дүртөйле районы «Ярыш»[119] газетасы редакциясе каршында башлап язучы шагыйрьләр һәм журналистларның әдәби түгәрәге[120] үзенең «Атака» дип аталган беренче альманахын[121] нәшер итә[122]. М. Җәлил «Коммунист» газетасының шул елгы 5 май санында аңа бәяләмә бастыра. Аерым алганда

---

[116] Муса Җәлил – документларда... – Б. 306.

[117] *Сталингдака барып* – Сталинград ул вакытта Түбән Идел краеның мәркәзе була.

[118] Хамматов Ш. Яңа документлар: Муса Җәлил кулъязмалары / Ш. Хамматов // Казан утлары. – 1983. – № 2. – Б. 171.

[119] *«Ярыш»* – 1931 елның 14 ноябреннән чыга, 1956–1962 дә «Хезмәт байрагы», 1962–1967 дә «Уңыш өчен», 1967–1993 тә «Ленин байрагы», 1993 тән «Юлдаш» исемнәре белән нәшер ителә.

[120] Түгәрәкнең җитәкчесе Габделхәмит Габделмәҗит улы Вахитов (1910–1976) була.

[121] Атака (ədəbi əlmənəx) / Çiucьsь kollektif. Bastrucьsь «Jarьş» gəzetь. – Dyrtille, 1934. – 24 b.

[122] Хәбибуллин Ф. Муса Җәлил фатыйхасы белән...

анда Бәдрүш Мокамай[123], укытучы Касыйм Гомәров (?–?), Гаффан Гафаров, (?–?), Һ. Камал (?–?) шигырьләренә анализ ясала, аларның уңышлы һәм кимчелекле яклары күрсәтелә. Язма шулай тәмамлана: «Сүз ахырында «Ярыш»ның бу башлангычын котлап үтәргә кирәк. Яшь язучыларны үстерүдә түбәнге матбугат зур роль уйный. «Ярыш» бу адымы белән башка район газеталарына үрнәк була ала. Ул язучылар съездына үзенең конкрет әзерлек эшен күрсәтте»[124].

1934 елның җәй башларында Татарстан Совет язучылары союзын оештыру эшләре башланып китә. «Кызыл Татарстан» газетасының шул елгы 5 июнь санында гаризалар бирү дәвам итүе, илле гаризага йомгак ясалып, егерме дүрт кешенең әгъза итеп билгеләнүе хәбәр ителә[125]. Татарстан Совет язучылары союзының беренче съезды 18 июньдә Татар Дәүләт академия театры бинасында була[126].

Билгеле булганча, М. Җәлил оештыру комитеты президиумына әгъзалыкка тәкъдим итүләрен сорап 20 июньдә гариза яза һәм Союзга кабул ителә.

Бу елда аның «Шигырьләр һәм поэмалар»[127] һәм «Орденлы миллионнар»[128] дигән җыентыклары басылып чыга.

1935–1939 елларда Мәскәүдә П. И. Чайковский исемендәге Дәүләт консерваториясе янында Татар опера студиясендә[129] әдәбият бүлеге мөдире булып эшли. Шул вакытларда аның рус телендә шигырьләр җыентыгы нәшер ителә[130].

1936 елда Әминә Сәйфуллинага[131] өйләнә. Бер елдан соң аларның кызы Чулпан[132] туа.

---

[123] *Бәдрүш Мокамай* – Бәдретдин Мөхәммәтҗан улы Мөхәммәтҗанов (1909–1944), шагыйрь, Бөек Ватан сугышында һәлак була.

[124] Җәлил М. Дүртөйле яшь язучылары // Җәлил М. Әсәрләр: 5 т-да / Томны басмага әзер.: Ф. Кадыйрова, Г. Хөснетдинова; фәнни мөх. З. Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 4 т.: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм биографик материаллар. – Б. 93–95.

[125] Төxfətullin K. Sovet Jazucьlarь Sojuzь / K. Төxfətullin // Qьzьl Tatarstan. – 1934. – 5 iyun.

[126] Бу хакта хәбәр ителә: Tatarstan Sovet Jazucьlarьnьn berence sjezdь // Qьzьl Tatarstan. – 1934. – 15 iyun.

[127] Çəlil M. Şiƣerlər həm poemalar / M. Çəlil. – Qazan: Tatgosizdat, 1934. – 270 b.

[128] Çəlil M. Ordenlь millionnar: Şiƣerlər çiьntьƣь / M. Çəlil. – Qazan: Tatgosizdat, 1934. – 122 b.

[129] Ул чакта Татар опера студиясе директоры булып танылган журналист, нашир, җырчы (баритон) Хәмит Камил улы Төхфәтуллин (1883–1941) эшли.

[130] Джалиль М. Стихи / Авториз. пер. с татар. А. Миниха / М. Джалиль. – М.: Госполитиздат, 1935. – 107 с.

[131] *Әминә Сәйфуллина* – Әминә Сәйфуллина-Җәлилова 1913 елның 21 июнендә Казанда приказчик булып эшләгән Котдус Шакир улы Сәйфуллин гаиләсендә туган. 1920 нең ахырында Мәскәүгә китә һәм Төзүчеләр техникумына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, шәһәрдәге «Теплоэлектроцентраль» заводында техник-конструктор булып эшли. Яшь гаилә башта Мәскәүдә яши, 1939 да Казанга күченеп кайта. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, кызы Чулпан белән Мәскәүгә китә. Анда төрле учреждениеләрдә, шул исәптән Госплан һәм Госснабта икътисадчы булып эшли. 2006 ның 13 декбарендә вафат була.

[132] *Чулпан* – Чулпан Муса кызы Җәлилова 1937 елның 10 апрелендә туган. М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетының рус бүлеген

1938 елның декабрендә опера студиясен тәмамлаучылар белән бергә Казанга Татар дәүләт опера һәм балет театры оештырыга һәм ачарга кайта, анда әдәби репертуар бүлеген җитәкли (1941 елга кадәр).

1939 елның 21–24 апрелендә Татарстан Совет язучылары союзының исәп-хисап җыелышында ул идарәнең яңа составына кертелә һәм җаваплы секретаре, шул ук елда 277 Сайлау округы буенча Казан шәһәр Советына депутат итеп сайлана[133].

Яңа вазифада аңа бик күп мәсьәләләрне хәл итүдә көч куярга туры килә. Аерым алганда алар: нәшриятка кәгазь алдыру, язучыларны торак белән тәэмин итү, аларның көнкүреш шартларын яхшырту, классикларның (Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури (1880–1934), Шәриф Камал (1884–1942) һ. б.) юбилейларын үткәрү, ТАССРның 20 еллык бәйрәмендә катнашу, төрле республикаларның Язучылар оешмалары белән элемтәләр урнаштыру, алар үткәргән әдәби-мәдәни чараларда катнашуларны хәл итү һ. б. Бу вакытларда ул аеруча СССР Язучылар союзы секретаре А. А. Фадеев (1901–1956) белән дустанә тыгыз элемтәдә торып эшли[134]. Каләмдәшләренә, аерым алганда Нур Баянга (1905–1945), Гомәр Бәшировка (1901–1999), Гази Кашшафка, Шәриф Камалга, Ибраһим Газига (1907–1971), Әхмәт Исхакка (1905–1991), Әхмәт Ерикәйгә (1902–1967) һ. б. иҗат характеристикалары яза[135].

Бу чорда ул Г. Тукайның шигырьләр җыентыгын туплап бастырып чыгара[136], М. Гафуриның «Сайланма әсәрләр»ен[137] редакцияләп нәшер итә. Шулай киң татар җәмәгатьчелеген башка халыкларның классиклары иҗаты белән якыннан таныштыруга күп көч куя. Мәсәлән, аның турыдан-туры катнашлыгында грузин шагыйре Шота Руствелиның (XII) «Юлбарыс тиресе ябынган батыр», Дагыстанның халык шагыйре Сөләйман Стальскийның (1869–1937) «Сайланма әсәрләр»е, украин шагыйре Тарас Шевченконың (1814–1861) шигырьләр җыентыгы, чуаш әдәбиятына нигез салучы Константин Иванов (1890–1915) әсәрләре татар телендә дөнья күрә[138].

Үзенең дә шигырьләр җыентыгы[139], «Балалар өчен беренче альбом»ы[140] һәм «Хат ташучы»[141] исемле поэмасы басылып чыга.

---

тәмамлый. «Художественная литература» нәшриятында эйдәп баручы фәнни мөхәррир булып эшли. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши.

[133] Безнең кандидатлар. Муса Җәлил // Совет әдәбияты. – 1939. – № 10–11. – Б. 12; Листовка кандидата в депутаты Казгорсовета Мусы Мустафовича Джалиля (Залилова) // Муса Җәлил – документларда... – Б. 559–561.

[134] Хамматов Ш. А. Фадеев һәм М. Җәлил дуслыгы / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1984. – 6 июль.

[135] Хамматов Ш. М. Җәлил каләмдәшләре турында: яңа документлар һәм мәгълүматлар / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1983. – 13 февр.

[136] Tuqaj Ƣ. Sajlanma əsərlər / Çəv. red. M. Çəlil / Ƣ. Tuqaj. – Qazan: Tatgosizdat, 1938. – 622 b.

[137] Ƣafuri M. Sajlanma əsərlər / M. Ƣafuri. – Qazan: Tatgosizdat, 1939. – 610 b.

[138] Хамматов Ш. М. Җәлил Тарас Шевченконы пропагандалый / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1984. – 7 авг.; *Аныкы ук.* Халыклар дуслыгы җырчысы / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1986. – 14 февр.

[139] Çəlil M. Şiƣerlər / M. Çəlil. – Qazan: Tatgosizdat, 1939. – 71 b.

Гомумән, 1931–1941 еллар аралыгында матбугат битләрендә аның әдәбият-сәнгать турында күп санда мәкаләләре, либреттоларга бәяләмәләре басыла, дөнья күрми калган байтак эчке бәяләмәләр дә архивларда саклана.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 13 июльдә Казанның Молотов районы хәрби комиссариаты тарафыннан Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сафларына чакырыла. Аны Курск өлкәсенең Марьино шәһәрендә оештырылган политработниклар курсына укырга җибәрәләр. Биредә дә иҗат белән шөгыльләнүен дәвам итә. «Әйдә, җырым», «Чулпанга», «Хуш, акыллым (Әминәгә истәлек)» дигән шигырьләр язганлыгы мәгълүм[142]. Казанда аның «Алтынчәч»[143], «Илдар (Лачыннар)»[144] опералары өчен язган либреттолары нәшер ителә.

1941 елның ноябрендә фашистлар армиясе Марьинога якынлаша башлагач, мәктәпне Щигры (Курск өлкәсе) шәһәренә күчерәләр. Аннан соң эшелонга төяп, Татарстанга – Минзәлә шәһәренә озаталар. Бөгелмә станциясеннән йөз километр араны курсантлар җәяүләп бара. Курслар Минзәлә педагогия училищесы бинасында 1941 елның 7 ноябреннән 1942 елның 1 гыйнварына кадәр була.

Анда укыганда М. Җәлил җәмәгать эшләрендә дә еш катнаша. Педучилищеда укучылар белән очраша, Дусай-Кичүдә, Сарсаз Тауларында, Тулбайда, Иске Мәлкәндә, Яңа Мәлкәндә һ. б. авылларда докладлар белән чыгышлар ясый. Дусай-Кичүдә булганда башлангыч мәктәп укытучысы Заһит Әхмәдиевләрдә (?–?) яши. Иҗат белән шулай ук актив шөгыльләнә: утызлап шигырь яза[145]. Курсларны тәмамлагач, шәһәр театрында озату кичәсе оештырыла. Педучилищеда укытучы булып эшләгән һәм М. Җәлил белән турыдан-туры аралашкан Мөхәммәт Гарифуллин (?–?) истәлегеннән күренгәнчә, шагыйрь анда «Шлем», «Минзәләдә культура», «Без китәбез», «Тырышып эшләгез», «Чыршы җыры», «Мактанчыкка сабак», «Бүләк» дигән шигырьләрен укый. Соңгы өчесе Минзәләдә чыга торган «Ленин байрагы» газетасында да басыла[146].

1942 елның 8 гыйнварында Татарстан Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында М. Җәлилне фронтка озату кичәсе оештырыла[147]. Анда дәүләт эшлеклеләре, әдипләр, композиторлар, журналистлар белән бергә чит ил язучылары да кат-

---

[140] Җәлил М. Балалар өчен беренче альбом / М. Җәлил. – Казан: Татгосиздат, 1940. – 17 б.

[141] Җәлил М. Хат ташучы (Поэма) / М. Җәлил. – Казан: Татгосиздат, 1940. – 72 б.

[142] Гарифуллин Д. Курсант Муса эзләре / Д. Гарифуллин // Соц. Татарстан. – 1975. – 31 дек.

[143] Җәлил М. Алтынчәч. Опера өчен либретто, 3 актта, 5 картинада пролог белән / М. Җәлил. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 100 б.

[144] Җәлил М. Илдар (Лачыннар). Опера өчен либретто, 4 пәрдәдә, 6 картинада / М. Җәлил. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 72 б.

[145] Хәкимова Г. Искә алсам, исем китә / Г. Хәкимова // Мәдәни җомга. – 2014. – 14 февр.

[146] Гарифуллин М. Муса Җәлил Минзәләдә / М. Гарифуллин // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 114.

[147] Хамматов Ш. Өлкән политрук Муса Җәлил Казанда / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1980. – 8 нояб.

наша. ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе Гали Динмөхәммәтовка[148] 23 гыйнварда язган хатында бу хакта үзе шулай яза: «Мин китәсе көнне иптәшләр зур мәҗлес җыйганнар иде. Сез районда булып килә алмадыгыз булса кирәк, Мөхәммәтов[149] һәм Тинчурин[150] иптәшләр бар иде. Мондый махсус кичә җыеп, анда Имаметдинов[151] һәм Кутуй[152] миңа карата артык зурайтып, күпертеп речь сөйләүләре миңа, әлбәттә, бик уңайсыз булды»[153].

Берникадәр Мәскәүдә резервта булганнан соң, М. Җәлил 1942 елның язында Волхов юнәлешендәге Икенче Удар Армиянең «Отвага» исемле газетасына хәрби корреспондент итеп билгеләнә. Андагы эшчәнлеге турында матбугатта шактый мәгълүмат табарга мөмкин[154].

1942 елның 26 июнендә Мясной Бор тирәсендә чолганышта каты яраланып[155], әсирлеккә төшә һәм Ленинград өлкәсенең Чусский станциясендәге хәрби әсирләр лагерена озатыла. Анда сентябрь азакларына кадәр булганнан соң, Латвиянең Двинск (хәзер Даугавпилс) шәһәрендәге, аннары Седльце лагерена, октябрь ахыры – ноябрь башында Польшадагы Демблин крепостена китерелә. Анда 1942 елның маеннан Гайнан Кормашев[156] җитәкчелегендәге яшерен партия оешмасы эшләп ки-

---

[148] *Гали Динмөхәммәтов* – Гали Афзалетдин улы Динмөхәммәтов (1892–1951), дәүләт эшлеклесе. 1938 елдан ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе.

[149] *Мөхәммәтов* – Мөхәммәтов Самат Әхмәт улы (1907–1942), хакимият эшлеклесе. 1938–1942 елларда ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетында пропаганда секретаре.

[150] *Тинчурин* – Закир Тинчурин (1895–1960), ул вакытта Совнакром рәисе урынбасары.

[151] *Имаметдинов* – Төхфәт Имаметдинов (?–?), 1940–1942 елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре (рәискә тиң) була.

[152] *Кутуй* – Гадел Кутуй (Кутуев Гаделша Нурмөхәммәт улы; 1903–1945), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

[153] Муса Җәлил – документларда... – Б. 423.

[154] Мәсәлән: Мустафин Р. Корреспондент газеты «Отвага» / Р. Мустафин // Веч. Казань. – 1981. – 3 февр.; Новый сотрудник редакции, Муса Джалиль // Респ. Татарстан. – 1996. – 1 июля; Хамматов Ш. Шагыйрь Волхов фронтында / Ш. Хамматов // Соц. Татарстан. – 1985. – 10 дек.

[155] «Мусаның сул як иңбашы яраланган иде, сөяге сынып, сул кулы салынып төшкән иде. Билендә һәм сул як кабыргаларында зур-зур гына умырылган яралары бар иде. Ядрә аның сул як билендәге ит кисәген мул итеп умырып алган. Двинскида сентябрь аенда да әле аның яралары төзәлмәгән иде. Аның яралары бер үк вакытта булганмы, әллә төрле вакыттамы – хәтерләмим. Ләкин ул яраларны мин үз күзем белән күрдем һәм массаж да ясадым»: Ганиев С. «Эчтән шартлатырга…» / С. Ганиев // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 129

[156] *Гайнан Кормашев* – Гайнан Нури улы Кормашев (1919–1944), укытучы, антифашист, 1919 елның 27 февралендә хәзерге Мари Республикасының Бәрәңге районы Куян авылында туган. Авылдагы җидееллык мәктәбен, Бәрәңге педагогия техникумын тәмамлый. Казакъстандагы Актүбә, аннары Куян авылы (1937–1938) мәктәпләрендә директор булып эшли. 1939 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла, Совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшә, «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы төзүчеләрнең берсе. 1944 елның 25 августында Плётцензее төрмәсендә

лә. 1943 елның гыйнвар башында Вустрау лагерена күчерелә. Ул анда 1943 елның апреленә кадәр була. Әсирлектә Гумеров[157] фамилиясе белән йөри. Шул елның февралендә ВКП(б)ның Берлин комитеты һәм әлеге яшерен оешма арасында элемтә урнаштырыла[158].

Әсир төшкән төрле милләт вәкилләреннән хәрби берәмлекләр төзү мәсьәләсе Германия җитәкчелеге тарафыннан СССРга каршы сугыш башланган вакытта ук карала. Ул Чит ил эшләре министрлыгында 1941 елның 30 июнендә үткәрелгән киңәшмәдә тикшерелә[159]. Татар әсирләре арасында эш алып бару өчен әүвәл 1942 елда Берлинда «Татар арадашчылыгы» дигән оешма барлыкка килә. Соңрак ул «Идел-Урал комитеты» дип атала. Аның беренче җитәкчесе Әхмәт Тимер[160] (1943 елның уртасына кадәр), аңардан соң Шәфи Алмас[161] була. 1944 елның 3–5 мартында Гер-

---

гильотинада (12 сәгать 06 минутта) җәзалап үтерелә. Куян авылындагы урта мәктәп аның исемен йөртә.

[157] 1944 елның 12 февралендә Германиянең Дрезден шәһәрендәге Өченче империя мәхкәмәсенең хөкем карарында да ул Гумеров (Gumerov) буларак язылган. Ә аның үлеме турында мәгълүмат теркәлгән документта Гумеров-Җәлил (Gumerov-Djalil) дип күрсәтелгән: Муса Җәлил – документларда... – Б. 527, 528; 529.

[158] Рыбалченко А. Ерткыч оясында / А. Рыбалченко // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 237.

[159] Төрле милләтләрдән төзелгән легионнар турында тәфсыйле: Гилязов И. Легион «Идель-Урал». Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха» / И. Гилязов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005 – 383 с.

[160] *Әхмәт Тимер* – Әхмәт Рәшит улы Яруллин, 1910 елның 14 (27) февралендә Самара губернасы Бөгелмә өязенең Әлмәт авылында (хәзер Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре) мулла гаиләсендә туган. 1929 да Төркиягә качып китә. Трабзон укытучылар интернат-мәктәбендә укый. Бу уку йорты 1934 тә ябылып, Истанбулдагы Хәйдәр паша мөгаллим мәктәбе белән берләшеп, лицей булып оеша. Ул аны 1935 тә тәмамлый. Шул елда Әнкарадагы Тел, тарих һәм география факультетына укырга керә. 1936 да Германиягә китә һәм Берлин университетына укырга керә. 1941 нең 17 июнендә Һамбург университетында диссертация яклый. Аннары Берлин университетында татар теле укыта. 1941–1943 тә Германия Чит ил эшләре министрлыгының радиопропаганда бүлегендә хезмәттәшлек итә. 1943 нең 22 июлендә фән докторы дәрәҗәсе ала. Шул ук елның 15 октябрендә Төркиягә китә. Хәрби хезмәтне үтәгәч, Баш музей идарәсендә эшли (1947–1951). Төрки мәдәниятне өйрәнү институтын нигезли һәм аның беренче директоры була (1961–1975). 1962 дә профессор дәрәҗәсе ала. 2003 нең 19 апрелендә шунда вафат була.

[161] *Шәфи Алмас* – Габдрахман Гыйбадулла улы Галиуллин сәүдәгәр, 1885 елда Казан өязе Дөбъяз төбәгендә туган. Мәскәүдә, Казанда, Оренбургта кибетләр тота. Ватандашлар сугышы вакытында Төркиягә китә һәм гражданлык ала. 1920 ләрдә Төркиянең Мәскәүдәге илчелегендә эшли. 1928 дән Германиядә яши. Бөек Ватан сугышы башлангач, немецлар тарафыннан пропаганда эшенә җәлеп ителә. 1942 дә хәрби әсирләр лагерьларында йөреп, алар алдында чыгышлар ясый, хезмәттәшлек итү өчен кадрлар сайлау белән шөгыльләнә. Ә. Тимердән соң «Идел-Урал» комитетының президенты, аның урынбасары Салих Фәйзуллин, оештыру эшләре җитәкчесе Гариф Солтан, капитан М. Кашапов, капитан Вафин, Идел-Уралның мөселман булмаган халыклары бүлеге җитәкчесе Иван Скобелев, полковник Шакир Алкаев, мәдәният мәсьәләләре буенча җаваплы «Tatar ədəbiats» журналы мөхәррире Га-

маниянең Грайсфальд шәһәрендә 200 делегат катнашлыгында уздырылган корылтайда «Идел-Урал төрек-татарлары мөстәкыйльлеге өчен көрәш берлеге» дигән исем ала[162].

«Идел-татар» легионы Польшадагы Радом шәһәре янындагы Едлино лагеренда оештырылып, 1942 елның 6 сентябрендә игълан ителә һәм аның командиры итеп майор Оскар фон Зеккендорф билгеләнә. Легионда хәрби берәмлекләр, ягъни батальоннар төзелә[163]. Мөселман хәрби әсирләре буенча Бөек мөфти Әмин әл-Хөсәени[164] янында җаваплы итеп Галимҗан Идриси[165] билгеләнә. Легионерлар арасында пропаганда эше алып бару өчен 1942 елның июлендә «Винета»[166] радиостанциясендә татар телендә радиотапшырулар редакциясе[167], «İdel-Ural»[168] дигән газетасы (1942 елның 15 ноябреннән)[169], «Tatar ədəbiatь»[170], татар һәм немец телләрендә

---

лим Айдагулов, «İdel-Ural» газетасы җитәкчесе Габдулла Ишмаев, редакция хезмәткәре Исламгулов, Даргибелдә һәм Беверунгендәге лагерьлар җитәкчесе Сабит Кунафин» (Гилязов И. Легион Идель-Урал... – С. 272) була. 1945 нең гыйнварына кадәр «Идел-Урал төрек-татарлары мөстәкыйльлеге өчен көрәш берлеге»нең җитәкчесе вазифасын үти. Сугыш тәмамланганчы Төркиягә китә һәм шунда 1954 тә вафат була.

[162] Гилязов И. Курултай в Грайсвальде: «Мы боремся за единение народов Идель-Урала и за образование свободного национального государства» / И. Гилязов // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2000. – № 3/4. – С. 58–73.

[163] Алар хакында тулырак: Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... С. 182–213.

[164] *Әмин әл-Хөсәени* – Мөхәммәд Әмин әл-Хөсәени (1895–1974), Йөрсәлим (Иерусалим) мөфтие, Фәләстыйнда гарәп милләтчеләре лидеры. Бөек Ватан сугышы вакытында немец-фашистлар белән хезмәттәшлек итә.

[165] *Галимҗан Идриси* – Галимҗан Ибраһим улы Идриси (1887–1959), җәмәгать, сәяси һәм дин эшлеклесе, журналист. Беренче бөтендөнья сугышы вакытыннан ук Германиядә яши. 1918–1925 елларда «Россия мөселман студентларына ярдәм оешмасы» президенты, 1922–1926 да Бохара республикасының Германиядәге рәсми вәкиле, 1924–1928 дә мөселман оешмасы җитәкчесе була. 1934 нең апреленнән Германия Чит ил эшләре министрлыгында фәнни хезмәткәр-консультант, 1939 ның маеннан бер үк вакытта Пропаганда министрлыгында гарәп илләренә радиопропаганда белән шөгыльләнә. Бөек Ватан сугышыннан соң Согуд Гарәбстанына китә һәм 22 сентябрьдә вафат була, җәсәде Германиянең Мюнхен шәһәре зиратында дәфен кылына.

[166] *«Винета»* – Германиянең Геббельс җитәкчелегендәге Пропаганда министрлыгы радиостанциясе.

[167] Аңа башта Тәмербәк Дәүләтшин (Тәмербәк Динмөхәммәт улы Дәүләтшин, 1904–1983), аннары Г. Идрисинең хатыны Шәмселбәнат Идриси җитәкчелек итә. Яшерен оешма тәкъдиме белән Әхмәт Симаев (1942 елның августыннан), Миңгали Газиев хезмәткәрләр булып эшли.

[168] Газетаның баш мөхәррирләре Кыям Галиев, Габдулла Ишмаев була.

[169] Басманың шеф-редакторы Шиһап Нигъмәти (Шиһабетдин Нигъмәтуллин, 1913–1995), хезмәткәрләре әүвәл Хәмит Нәүруз, Газиз Уразай, Гафар Җәмалиев, Ахун Таһиров, Миңнегали Газиев, Шигай Нәҗип, соңрак Миңнегол Гарипов, Бари Фәтхуллин, Фатыйх Азизбаев, Әсфәндияр Чынбай (1908–1992) була.

[170] Журналны чыгаручы һәм баш мөхәррире Ш. Алмас, мөхәррире Г. Хәмиди (Әнвәр Галим (Айдагулов, ?–1988) була.

«Germanca-tatarca beleşmə – Deutsch-tatarisches Nachrichtenblatt» (1943 елның апреленнән 1944 елның июленә кадәр)[171] исемле журналлар нәшер ителә. Алар, нигездә, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис басма була.

Мондый мөмкинлекләрдән файдаланып, дошманга каршы аның үзендә көрәшергә кирәк дигән карарга килгән патриотлар шунда туплана башлый. Алар гражданский киемдә, чагыштырмача иректә йөрү хокукына ия була[172]. Эшне координацияләү максатында Берлинда 4 нче номерлы ирек комитеты төзелә. Бу уңай белән Әхмәт Симаевның[173] Фәйзелхак Мингалинга[174] әйткән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Көрәшне башлау өчен башта аяк-кулларны богаудан чишәргә, ягъни лагерьдан котылырга, ышанычлы дуслар белән бергә тупланырга кирәк. Әгәр дә мин бу лагерьдан чыга калсам, ничек тә моннан берничә кешене үзебезнең янга тартырга тырышырмын...»[175].

1943 елның июнендә М. Җәлил белән очрашкач, ул аңа шулай ди: «Без, – диде Муса, – легиончылар арасында һәм Германия завод-фабрикаларына куып китерелгән совет гражданнары арасында, дошманга каршы пропаганда алып барырга, төрле өндәмәләр, листовкалар таратып, легиончыларны кулларындагы кораллары белән совет солдатлары ягына чыгарга әзерләргә тиешбез. Ә лагерьдагы совет гражданнарына аларның озакламый Совет Армиясе тарафыннан азат ителәчәкләрен аңлатырга, җиңүне якынайту өчен һәртөрле корткычлыклар эшләргә өндәргә тиешбез!»[176].

---

[171] Журналның баш мөхәррире Гариф Солтан (Гариф Нигъмәтулла улы Солтанов, 1923–2011) була.

[172] Мәсәлән, җәзалап үтерелгәннән соң тутырылган карточкалары буенча, Муса Җәлил Берлинда Һавелштрассе, 9; Гариф Шабаев – Фридрихштрассе, 247, Әхмәт Симаев – Вильмерсдорфштрассе, 15 адреслары буенча яшәгәнлекләре мәгълүм.

[173] *Әхмәт Симаев* – Әхмәт Садретдин улы Симаев, журналист, антифашист, 1915 елның 28 декабрендә Пенза губернасы Краснослободск өязе (хәзер Мордва Республикасы) Усть-Рахмановка (Яңа Аллагол) авылында туган. Мәскәүдә җидееллык мәктәпне, техникум тәмамлый. 1933 елда Мәскәү метрополитены төзелешендә катнаша, татар телендә чыга торган «Метрострой коммунисты» газетасында язышa башлый. 1936 да Мәскәү янындагы Воскресенск шәһәренә күчә һәм тулысынча газета эшенә бирелә. 1939 да Мәскәү дәүләт педагогия институтының әдәбият факультетына читтән торып укырга керә. 1940 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышын десантчы булып каршылый. 1942 нең март аенда әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы төзүчеләрнең берсе. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 24 минутта) җәзалап үтерелә. Иске Синдрау авылы мәктәбе диварына истәлек тактасы куела.

[174] Фәйзелхак Мингалин (?–?), укытучы, антифашист, хәзерге Татарстан Республикасының Зәй районы Аксар авылында туган. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк яраланып, әсирлеккә төшә. Берлин янындагы Вольһайде лагеренда Ә. Симаев белән таныша. Берлинда радио-пропаганда бүлегенә эшкә беркетелә. 1943 елның августында гестапо тарафыннан кулга алына. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, 1946 да туган илгә кайта. 1947 дә «дошман файдасы өчен хезмәт итүчеләр» сыйфатында хөкем ителә.

[175] Мингалин Ф. Алар мәңге онытылмас / Ф. Мингалин // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 262.

[176] Мингалин Ф. Күрс. хезм. – Б. 264.

Гомумән, 1943 елның язына көчле яшерен оешма барлыкка килә.

«İdel-Ural» газетасы редакциясендә эшләгән Рәхим Саттарны[177] «Идел-Урал» комитеты президенты Ш. Алмас, хәтта, Советлар ягыннан махсус җибәрелгән дигән фикергә килә һәм зондерфюрер Людерзинга 1943 елның 3 маенда язган донесениесендә шулай ди: «Соңгы вакытта мин Саттаровның немецлар ягына хезмәткә күчүе хакында таныклыгы бар дип ишеттем. Әгәр бу, чынлап та, шулай икән, бу хәл Саттаровның большевиклар тарафыннан безгә мөмкин кадәр зыян китерү һәм безнең уртак милли хезмәтебезгә комачаулык итү өчен махсус җибәрелгәнлеге хакында шигебезне тагын да ныграк раслый. Редакциядә эшләү өчен бөтенләй яраксыз булуы сәбәпле, Саттаровны кире легионга җибәрергә, ә аның урынына башка яраклы кеше табарга кирәк»[178].

Яшерен пропаганда алып бару максатында 1943 елның апрелендә Радомда әдәби-музыкаль капелла төзелә. Едлино лагерена китерелгән Рушад Хисаметдинов[179]

---

[177] *Рәхим Саттар* – Габдерәхим Сөләйман улы Габдессаттаров, шагыйрь, журналист, 1912 елда хәзерге Башкортстан Республикасы Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында мулла гаиләсендә туган. Уфада татар балалары гимназиясендә укый (1920–1926). Алты сыйныфны тәмамлагач, Казандагы индустриаль техникумның әзерлек курсларына керә. Икенче курста укыганда авырып, туган авылына кайта. Комсомол оешмасы төзелгәч (1927–1928), аны секретарь итеп сайлыйлар. Аннары Донбасста шахтада, Башкортстанның Учалы районында урман хуҗалыгында эшли. Казанда «Обоздеталь» заводына эшкә керә. Кызыл Армия сафларына чакырылгач, Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. 1937 нең көзендә Казанга кайта һәм авиация институтында завхоз, Татарстан Мәгариф халык комиссариатында кадрлар бүлеге мөдире булып эшли. Аннары «Яшь сталинчы» газетасы редакциясенә эшкә керә. Совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 нең көзендә хәрби хезмәткә алына. 1942 нең 27 июнендә, Вязьма районы Угра авылы янында дошман тылында уңышсыз десант төшерү вакытында әсирлеккә төшә. «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы эшендә катнаша, Берлин төркемендә тора. 1943 нең июлендә биш кешелек төркем составында урманчы поляк ярдәмендә партизаннар ягына кача. Шуннан соңгы язмышы билгеле түгел.

[178] Басыйров Х. Ватанга тугры калдылар: документаль повесть / Х. Басыйров, А. Басыйров. – Казан: Татар. кит. нәшр,. 2017. – Б. 273.

[179] *Рушад Хисаметдинов* – Рушад Мөхәммәтбилал улы Хисаметдинов, ветеринар, антифашист, 1911 елның 20 октябрендә Верный (хәзер Алматы) шәһәрендә туган. 9 сыйныфны тәмамлаганнан соң, Әүлия-Атадагы ветеринар-зоотехник бүлегендә укый (1929–1932). Семипалатинск өлкәсендәге «Кокпекты» совхозында ветврач булып эшли. Аннары, үзе теләп, Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1940 та демобилизацияләнгәч, Алматы өлкәсендәге Или районында өлкән ветврач була. Бөек Ватан сугышы башлангач, Көньяк-көнбатыш фронтта 79 нчы аерым Кавалерия дивизиясенә хезмәткә алына. 1942 нең 14 июлендә Миллерово станциясе тирәсендә чолганышта калып, әсирлеккә төшә. Этап белән Демблин крепостена китерелә. Анда Г. Кормашов, М. Җәлил, Г. Фәхретдинов (Дим Алишев) белән таныша. Аннан Ротвайль лагерена озатыла һәм 1943 нең язында Едлинога китерелә. «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы эшендә катнаша. Музыкаль капелла җитәкчесе була. 1943 нең 11 августында кулга алына. 25 октябрьдә Моабит, аннан соң Тегель төрмәсенә озатыла. 1944 тә Франциянең Югары Луара департаменты Ле-Пьюи шәһәренә китерелә. Аннан поезд белән янә Германиягә алып киткәндә Макон бе-

шулай яза: «Килгән көнне үк мин музыкантлар белән таныштым, чөнки мине алар белән бер баракка куйдылар. Анда Маликов Гарәф бар иде. Ул үзе Уралдан, соңыннан ул яшерен оешманың члены булды һәм Франциядә, партизаннар белән бергә, немецларга каршы көрәште. Ходжаев Кәрим – Астрахань егете, скрипкада уйнады. Кечкенә буйлы Сабитов та Астраханьнан иде. Ул мандолинада уйнады һәм спектакльләрдә кызлар ролен башкарды. Шат күңелле, сүз тыңлаучан егет иде. Самирханов дигән чибәр егет тә кызлар ролен башкара һәм Сабитов белән татар биюләрен оста бии иде. Николай Малышев – урта яшьләрдәге Горький кешесе – гитарада оста гына чирттерә, чечетканы бии иде... Одесса консерваториясе студенты Борисны (фамилиясен белмим), Бари Кәримов исеме биреп, опера театры артисты сыйфатында алып килдек. Борис – милләте белән еврей иде, аның еврей икәнен белсәләр, немецлар, әлбәттә, исән калдырмаячаклар иде. Немецлар аны татар дип кабул иттеләр булса кирәк. Ул үзе татарча җырларга бик тиз өйрәнде, ягымлы тавышы белән «Нигә, нигә...»не һ. б. җырларны уңышлы башкара иде»[180]. Соңыннан ул үзе капелланың гомуми җитәкчесе була.

«Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы эшендә катнашкан Фәрит Солтанбәков[181] капелланы шулай тасвирлый: «Артистлар

---

лән Шалон шәһәрләре арасында, Турню дигән төбәктә самолетлар эшелонны бомага тоталар. Шуңардан файдаланып качып өлгерә һәм француз партизаннарына барып кушыла. Анда 1944 нең декабренә кадәр немец-фашистларга каршы сугыша. 1945 нең ахырында туган илгә – Кыргызстанның Ош шәһәренә күчкән гаиләсенә кайта. Башта андагы ит комбинатының җитештерү-контроль бүлегенә эшкә урнаша. 1949 ның язында кулга алына, Төркестан хәрби округының трибуналы аны «Хәрби антын бозып, легионда фашистларга булышкан» дип, үлем җәзасына хөкем итә. Соңыннан карарга үзгәртмә кертелеп, 25 елга лагерьга җибәрелә. Кемерово өлкәсендәге «Глубинка», ерак төньяктагы Яна елгасы буендагы «Депутатский» лагерьларында күп газаплар кичергәннән соң, 1956 ның ахырында иреккә чыгарыла һәм Ош шәһәренә кайтып, авыл хуҗалыгы идарәсендә баш зоотехник, аннары Фрунзе, Калинин исемендәге колхозларда җитәкче булып эшли. 1967 дә СССР Югары судының хәрби коллегиясе тарафыннан реабилитацияләнә. 1974 кә кадәр, геологик эзләнү экспедицияләрен атлар белән тәэмин итү базасы директоры вазифасын башкара. 1992 нең 28 августында вафат була.

[180] Хисаметдинов Р. Уттан ялкынга... / Р. Хисаметдинов // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 163; 165.

[181] *Фәрит Солтанбәков* – Фәрит Сәхи улы Солтанбәков, 1940 елда Сәмәрканд дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Үзбәкстан ССРның Кашкадәрья өлкәсендәге Шәһризәбс шәһәрендә җидееллык мәктәптә укыта, укыту эшләре буенча директор урынбасары була. Кызыл Армия сафларына алынгач, Житомир өлкәсенә офицерлар курсына җибәрелә. Бөек Ватан сугышы бушлангач, ул хезмәт иткән часть Шепетовка шәһәре янында чолганышта кала. Авыр яраланган Ф. Солтанбәков 1941 нең 6 июлендә әсирлеккә төшә. Перемышль, Раво-Русс, Львов хәрби әсирләр лагеренда булганнан соң, Демблинга, аннан Едлинога китерелә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзалары белән таныша, капеллага кертелә. 1943 нең августында Уездом лагеренда концерт куйган вакытта кулга алына һәм Берлинга озатыла. 1944 нең августында гомерлек каторгага хөкем ителә һәм Лембург шәһәрендәге 12-А штраф лагереана җибәрелә. 1945 нең апрелендә әсирлектән азат ителә һәм декабрь аена кадәр Со-

труппасында 14 кеше исәпләнә иде. Уникебез бер баракта торабыз. Музыкантлар 9 кеше, шулардан 3 се скрипач, икесе гармоньчы, икесе мандолинада һәм икесе гитарада уйный. Үз гомерендә театрда эшләгәне булмаса да, Курмаш труппаның режиссёры булды. Муса Җәлил инде без килгәнче үк Рушат Хисаметдиновны капелла җитәкчесе итеп билгеләгән иде. Аның да моңарчы әле музыкант булганы юк иде. Шушы көнгәчә сәхнәгә бер генә тапкыр да аяк басмаган Хәсәнов һәм Батталов исә артист исеме алдылар. Мин дә мандолинада начар уйныйм: нота белән уйнау түгел, хәтта нотаны укый да белмим. Ләкин шулай да музыкант булырга туры килде. Фәхретдинов һәм Әмиров[182] труппаның җырчылары иде»[183]. Алар төрле лагерьларда концертлар куялар, инсценировкалар күрсәтәләр. Шул арада яшерен рәвештә листовкалар тараталар.

1943 елның сентябрендә Чернигов өлкәсе Прилуки шәһәре лагереннан качкан Ян Габдуллинның[184] ВКП(б) Үзәк Комитетына язган аңлатмасы буенча дошман территориясендә немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы барлыгы мәгълүм була[185].

«Идел-Урал» легионының 825 нче батальонын һәм башкаларын Михаил Бирюлин[186] җитәкчелегендәге 1 нче Витебск партизаннар бригадасы, француз партизаннары ягына чыгаруда Хөсәен Мөхәммәтов[187], Галимҗан Галиев[188], Фидият Рәхимов[189] хәлиткеч роль уйный.

---

вет армиясе сафларында хезмәт итә. Сугыштан соң 1978 гә кадәр Карши педагогия техникумында математика укыта.

[182] *Әмиров* – чын исеме Шәриф Гарифҗанов.

[183] Солтанбеков Ф. Аларны ил онытмас / Ф. Солтанбеков // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 192.

[184] *Ян Габдуллин* – Муллаян Тимеркәй (Тимергали) улы Габдуллин, укытучы, 1906 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзер Башкортстан Республикасы Туймазы районы) Яңа Арсланбәк авылында туган. 1925 тә Бәләбәй педагогия училищесын тәмамлый, укытучы булып эшли, Токчуран волостенда комсомол секретаре була. 1933–1937 дә Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында 1942 нең 29 июнендә каты яраланып, әсирлеккә төшә. Күп кенә концлагерьлар аша үтә. 1943 нең 19 сентябрендә, Чернигов өлкәсе Прилуки шәһәре янында фронт сызыгын исән-имин үтеп, ВКП(б) Үзәк Комитетына аңлатма язып, дошман тылында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы барлыгын хәбәр итә. Өлкән лейтенант Ян Габдуллин 1944 нең 5 мартында Украинаның Хмельницк өлкәсе Грищевск районы Сосновка авылы янында батырларча һәлак була.

[185] Низаметдинов З. Шагыйрьнең тугры дусты / З. Низаметдинов // Кызыл таң. – 2006. – 15 февр.

[186] *Михаил Бирюлин* – Михаил Фёдорович Бирюлин (1912–1999), полковник, Витебск җирлегендә партизаннар хәрәкәте оештыручыларның берсе, 1 нче Витебск партизаннар бригадасы командиры.

[187] *Хөсәен Мөхәммәтов* – Хөсәен Сафа улы Мөхәммәтов, антифашист, 1916 елда Уфа губернасы Бөре өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Чакмагыш районы) Кәшәк авылында туган. Үзбәкстанның Янги-юль станциясендәге балалар йортында тәрбияләнә. Туган якларына кайтып, 1933 тән Чакмагыш почта бүлегендә, МТСта эшли. 1937 нең октябрендә Кызыл Армия сафларына чакырыла, кече командирлар курсында укый. Кече лейтенант, илнең Көнбатыш чигендә 579 артиллерия полкының элемтә взводы командиры сыйфатында

М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең немец-фашистларга каршы алып барган яшерен эшчәнлеге хыянәтче Мәхмүт Ямалетдинов [190] тарафыннан фаш ителә.

---

1941 елның июнендә әсирлеккә төшә: Седльце, Едлино һ. б. лагерьларда була (Ул хәбәрсез югалган дип исәпләнелә һәм аның гаиләсенә 1942 елның 1 маеннан акча түләүне туктату турында Көньяк Урал хәрби округының финанс бүлегеннән Чакмагыш хәрби комиссариатына рәсми хәбәр килә). «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы эшендә катнаша. 825 нче батальонны беларус партизаннары ягына алып чыгуда турыдан-туры актив катнаша. Ватанга хыянәт итүдә гаепләнеп, 1944 нең 1 мартында җиде елга хөкем ителә һәм Ерак Көнчыгышка, ягъни Амурдагы Комсомольск шәһәре тирәсендә урман кисү эшенә җибәрелә. 1950 елда ирекккә чыгарыла. Кыргызстан ССРның Токтагул шәһәрендә яшәп, район хастаханәсендә баш табибның хуҗалык эшләре буенча урынбасары булып эшли. 1968 дә электр хуҗалыгында завхоз була. 1969 ның 21 гыйнварында тулысынча аклана.

[188] *Галимҗан Галиев* – Галимҗан Гарифулла улы Галиев, антифашист, 1916 елның 24 февралендә Уфа губернасы Стәрлетамак өязе (хәзер Башкортстанның Стәрлетамак районы) Югары Усылы авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, урман техникумында укый. Бөек Ватан сугышы башлангач, хәрби хезмәткә алына. Фронтта чолганышта калып, әсирлеккә төшә. Острув-Мазовецка, Седльце, Едлино лагерьлары аша үтә. «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы эшендә катнаша. Ул анда Галиев Гари буларак билгеле була. 825 нче батальонны беларус партизаннары ягына алып чыгуда турыдан-туры актив катнаша. Партизаннар сафында ул 1943 нең көзенә кадәр булып, рота командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Сугыштан соң Казакъстанның Шымкент (Чимкент) шәһәрендә яшәп, 1986 ның 9 гыйнварында вафат була.

[189] *Фидият Рәхимов* – Фидият Хан улы Рәхимов (?–?), антифашист, хәзерге Башкортстан Республикасының Кыйгы районында туган. Күрше Балакатай районының Үтәш авылында укый. Сугышка кадәр хисапчы булып эшли. Кызыл Армия сафларына чакырылгач, Фрунзе шәһәрендә хәрби пехота училищесында бер айлык курслар үтеп лейтенант дәрәҗәсе ала. 1942 елда Рота командиры сыйфатында Волхов фронтында 2 нче Удар армия составында сугышка керә. Сентябрь ахырында каты яраланып, әсирлеккә төшә. Гатчина, Вильнюс, Шауляй, Демблин, Едлино лагерьларында булганнан соң, «Идел-Урал» легионы составында Франциягә озатыла. 1944 нең июлендә Ф. Рәхимов җитәкчелегендә легионерларның беренче төркеме Сент-Анжел авылы янында француз партизаннары ягына чыга. Аның сугышчылары Уссель шәһәре өчен сугышта катнаша. Ул Франциянең иң зур бүләге – «Почётлы легионер» ордены белән бүләкләнә. Тюль шәһәрендә совет гражданнарын СССРга җибәрүне оештыру пункты җитәкчесе була. Сугыштан соң Байкал аръягы округында хәрби хезмәтен дәвам итә. 1946 да хәрби хезмәтен калдырып, укытучы булып эшли башлый. Озакламый кулга алынып, егерме биш елга хезмәт лагерена озатыла. 1955 тә ирекккә чykkаннан соң, Уфа шәһәрендә яши.

[190] Мәхмүт Ямалетдинов 1921 елда туган. Мәктәпнең сигезенче сыйныфын тәмамлагач, нотариаль конторада секретарь булып эшли. 1940 та Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә үк каты яралана. Аны Литвадагы Паберже төбәгендә поляклар яшәгән хуторда калдыралар. Икенче көнне әсирлеккә төшә. Тильзит шәһәреннән ерак булмаган лагерь лазаретына китерелә. 1943 нең башларында Едлино лагерена озатыла һәм анда «Идел-Урал» легионына кертелә, унтер-офицер чины бирелеп, отделение командиры итеп куела. Аның әләге буенча «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзалары кулга алына. 1944 нең җәендә башка унҗиде ле-

1943 елның 10 августында М. Җәлил Варшавада, ә 11 августта башкалар кулга алына. Аларны 12 августта «Павиак» дип аталган төрмәгә китерәләр, аннары Берлинга озаталар.

1944 елның 12 февралендә Германиянең Дрезден шәһәрендәге Өченче империя мәхкәмәсе М. Җәлилне һәм аның ун көрәштәшен: Гайнан Кормашев, Фуат Сәйфелмөлеков[191], Абдулла Алиш, Фуат Булатов[192], Гариф Шабаев[193], Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов[194], Зиннәт Хәсәнов[195], Әхәт Атнашев[196], Сәлим Бохаровны[197] «дош-

---

гионер белән Краков шәһәрендә юкка чыга һәм партизаннар отрядында пәйда була. 1945 нең маенда Львов шәһәреннән ерак булмаган фильтрация лагеренда тикшерү үтә, аңа дәгъва белдерелми. 1950 елның 24 апрелендә Казакъстан ССРның Костанай өлкәсендәге Боровский поселогында кулга алына. Аңа карата хәрби трибунал мәхкәмәсе чыгарган хөкем карары 1951 нең 19 гыйнварында гамәлгә ашырыла.

[191] *Фуат Сәйфелмөлеков* – Фуат Хаҗиәхмәт улы Сәйфелмөлеков, икътисадчы, антифашист, 1916 елның 16 июлендә Ташкент шәһәрендә туган. Казакъстандагы Казалы шәһәрендә урта мәктәпне, Куйбышев исемендәге Сәмәрканд халык хуҗалыгы институтын (1938) тәмамлый. 1938 нең 15 ноябреннән Таҗикстан ССРы Сәүдә Халык комиссариатында экономист-товаровед булып эшли башлый. 1940 ның 3 февралендә Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышында Брянск тирәсендә әсирлеккә төшә, «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. 1944 елның 25 августында Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 09 минутта) җәзалап үтерелә.

[192] *Фуат Булатов* – Фуат Зыятдин улы Булатов, инженер, антифашист, 1913 елның 25 февралендә Уфа губернасы Стәрлетамак өязе Мәләвез авылында (хәзер шәһәр) туган. Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтын тәмамлый. Сугыш башланыр алдыннан Кырымда юл эшләре төзелешендә эшли. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшә, «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. 1944 елның 25 августында Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 15 минутта) җәзалап үтерелә. 2025 нең 25 августында Мәләвез шәһәренең Тарих һәм туган якны өйрәнү музее бинасы диварына аңа багышланган горельев урнаштырыла.

[193] *Гариф Шабаев* – Гариф Хафиз улы Шабаев, финанс хезмәткәре, антифашист, 1907 елның декабрендә Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзер Башкорстан Республикасы Ярмәкәй районы) Иске Турай авылында туган. Узган гасырның егерменче елларында гаиләләре Урта Азиягә күченеп киткәч, анда башлангыч белем ала, Казанга кайтып тугызъеллык мәктәпне тәмамлый. 1928–1929 да Каюм Насыйри исемендәге татар педагогия техникумында башта техник секретарь, укыту бүлеге мөдире була. Аннары бухгалтерлык курсларын тәмамлый һәм янә Урта Азиягә китеп, Алты Арык районында, Фәрганә, Ташкент шәһәрләрендә дәүләт иминияте (страхование) агенты булып эшли. 1938 елда Үзбәкстан ССРы Финанс наркоматында эшли. 1941 елда үз теләге белән Бөек Ватан сугышына китә. Август аенда әсирлеккә төшә, «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 21 минутта) җәзалап үтерелә. Туган авылында бюсты куела.

[194] *Абдулла Батталов* – Абдулла Вәзыйх улы Батталов, антифашист, 1916 елның 1 маенда хәзерге Татарстан Респбликасының Алексеевск районы Олы Тигәнәле авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң колхозда эшли. 1937 дә Кызыл Армия сафларына чакырыла. Аягы авырту сәбәпле демобилизацияләнә. 1941 елда, Бөек Ватан сугышы башлану белән, армиягә алына. Шул ук елда әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында не-

манга ярдәм күрсәтү, хәрби көчне таркату», «дезертирлык», «хәрби хыянәт», «хәбәр итмәү» өчен үлем җәзасына хөкем итә[198]. Берникадәр вакыт (март ае) Дрезден төрмәсендә тотканнан соң, аларны Шпандау, Берлиндагы Тегель төрмәләренә күчерәләр.

Соңгы вакытларда табылган документлардан күренгәнчә, Ә. Симаевны ярлыкауны сорап Г. Идриси Бөек мөфти Әмин әл-Хөсәени исеменә хат юллаган булган. Ул «Хөкем ителүче Төркестан даирәсендә яхшы шагыйрь буларак таныш. Үзенең тәҗрибәсезлеге аркасында шундый хөкем карары чыгаруга китерә торган эшкә дучар булган... Үзенең поэтик осталыгы белән танылган мәхбүскә карата хөкем карары үтәлү гомуми ризасызлык барлыкка китерергә, киң ислам даирәсе тарафыннан күтәреп алынырга, соңыннан ислам илләрендәге дошман кулындагы пропагандада бозып файдаланырга мөмкин»[199]. Баш мөфти үз чиратында Германиянең Чит ил эшләре министрлыгына мөрәҗәгать итә. Бу оешма Окупацияләнгән Көнчыгыш җирләр эше буенча минстрлыкка һәм Окупацияләнгән Көнчыгыш җирләр эше буенча вер-

---

мец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 27 минутта) җәзалап үтерелә. Авыл мәктәбе аның исемен йөртә.

[195] *Зиннәт Хәсәнов* – Зиннәт Хөснулла улы Хәсәнов, сәүдә хезмәткәре, антифашист, 1916 елның 16 декабрендә хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районы Иске Кәшер авылында туган. Казанда сәүдә техникумын тәмамлый (1936–1939). Кызыл Армия сафларында ул кече командирлар әзерләү курсларында укый. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 30 минутта) җәзалап үтерелә. Авыл мәктәбе аның исемен йөртә, һәйкәл куела.

[196] *Әхәт Атнашев* – Әхәт Мәхмүт улы Атнашев, финанс хезмәткәре, антифашист, 1917 елның 12 декабрендә Төньяк Казакъстанның Петропавловск шәһәрендә туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлый. Степняк шәһәрендә бухгалтерлар курсына укырга керә. 1938 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышында 1942 нең 22 июнендә яраланып, әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 33 минутта) җәзалап үтерелә.

[197] *Сәлим Бохаров* – Галләнур Мостафа улы Бохараев, финанс хезмәткәре, антифашист, 1916 елның 15 июлендә хәзерге Башкортстан Республикасының Кыргыз-Миякә авылында туган. Казанда финанс курсларында укый. Аннары туган якларында дәүләт банкының район бүлегендә бухгалтер булып эшли. 1940 та Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышы вакытында әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы. Плётцензее төрмәсендә гильотинада (12 сәгать 36 минутта) җәзалап үтерелә. Туган авылында аның исемендә парк булдырыла, анда каһарманның бюсты куела.

[198] Хөкем карарының кулдан язылган өземтәсе 2001 елның гыйнвар аенда Прага шәһәре архивында табыла һәм ул «Кормаш һәм тагын 10 кеше» дип атала: Мостафин Р. Җәлилчеләр турында яңа мәгълүмат Прагада табылды // Муса Җәлил турында истәлекләр / Төз. Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – Б. 306–309.

[199] Гилязов И. А. «Был одним из главных зачинщиков подпольной группы…»: новые документы об Ахмете Симаеве / И. А. Гилязов // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2020. – № 3. – С. 96.

махтның Югары командалыгының рейхминистрына хат җибәрә. Ләкин алар барысы да ярлыкауны кире кагалар. Бу Михаил Иконников истәлегендәге мәгълүмат белән дә раслана. Аннан күренгәнчә, 1944 елның июнь ахырында, август башларында төрмә амбулаториясендә чират көткәндә Ә. Симаев үзе әйткән сүзләргә нигезләнеп, шулай ди: «Ул миңа үлем карарын раслау килгәнлеген һәм аларны җәзага илтергә тиешлекләрен әйтте»[200].

Хөкем ителгән мәхбүсләр Тегель төрмәсеннән Плётцензее төрмәсенә китереләләр. Ш. Алмасның күрсәтмәсе буенча мулла Гани Госманов[201] 25 августта камерага аларны бәхилләтү өчен Коръән[202] алып керә[203]. Хушлашып бер сәгать үткәннән соң, М. Җәлил (12 сәгать 18 минутта) һәм аның көрәштәшләре гильотинада җәзалап үтерелә. Бу кара эшне Германиянең баш палачы Эрнст Раендель[204] башкара[205].

Илдә әле бул хәлләр билгеле булмый. Казанда аның рус телендә шигырьләре һәм поэмалары җыентык булып басылып чыга[206].

1945 елның апрель ахырында Берлинны штурмлауда һәм Моабит төрмәсен азат итүдә катнашкан 79 нчы пехота корпусында элемтә батальонында хезмәттә булган П. Г. Крель (1894–1953) төрмә ишегалдында яртылаш янган китаплар, кәгазьләр арасыннан М. Җәлилнең соңгы хатын табып ала һәм аны июль аенда Мәскәүгә, СССР Язучылар союзы җитәкчесе А. А. Фадеевка җибәрәләр. Ул исә бу хакта Ә. Җәлиловага 1946 елның 18 июнендә хат аша хәбәр итә[207]. «Хатны алу белән Әминә ханым Мәскәүдәге Язучылар союзына килә (ул үзе дә бу чорда Мәскәүдә

---

[200] Иконников М. Фашист тоткынлыгында / М. Иконников // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 258.

[201] Гани (Габделгани) Госманов 1892 елның 4 (17) июнендә Семипалатинск шәһәрендә туган. Беренче Бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшә һәм Германиядә төпләнеп кала. Бөек Ватан сугышы вакытында «Татар комитеты»нда мулла вазифасын башкара. 1950 нең җәендә Фильофингда вафат була.

[202] Бу Коръәнне М. Госманов 1992 елда Америкага баргач, Габдулла Вафалы (1915–1998) исемле кешедә күрә. Килешү буенча, ядкяр Бөтендөнья Татар конгрессы корылтаенда киң җәмәгатьчелек алдында тантаналы рәвештә тапшырылырга тиеш була. Ләкин, ниндидер сәбәпләр аркасында әлеге вакыйга булмый кала. Г. Вафалы аны М. Госмановка бирә. Хәзер Коръән Татарстан Республикасының Милли музее фондында саклана: Госманов М. Соңгы истәлек / М. Госманов // Татарстан. – 1993. – № 7. – Б. 55–59; – № 8. – Б. 20–26.

[203] Бу хакта ул Берлинда «Идел-Урал» комитеты тарафыннан татар телендә нәшер ителүче «Татар әдәбияты» журналының мөхәррире Әнвәр Галимгә (Айдагулов, ?–1988) 1945 елның язында сөйли. Кәгазьгә төшерелгән бу истәлек басылып чыкты: Мостафин Р. Җәлилчеләнең соңгы минутлары / Р. Мостафин // Татарстан. – 1993. – № 1. – Б. 50–53.

[204] Эрнст Раендель (1899–1945/46) – Белоруссиянең Брест шәһәрендә асып үтерелә.

[205] Мостафин Р. Муса Җәлил эзләреннән / Р. Мостафин // Азат хатын. – 1973. – № 6. – Б. 7.

[206] Джалиль М. Письмо из окопа: Стихи и поэмы / М. Джалиль. – Казань: Татгосиздат, 1944. – 44 с.

[207] Муса Җәлил – документларда... – Б. 476–477.

яши) һәм иренең язмасы белән таныша. Шулай итеп, Җәлил батырлыгы турындагы беренче хәбәр илгә кайтып җитә...»[208]. Әмма озакламый ул хат эзсез югала.

М. Җәлилнең гарәп хәрефләре белән язылган беренче дәфтәрен Моабит төрмәсеннән Габбас Шәрипов[209] алып чыга. Еллар үткәч язучы Рафаэль Мостафинга (1931–2011) язган хатында бу хакта шулай ди: «Төрмәдә җыештыручы булып эшләүче, камераларга кереп-чыгып йөри ала торган тоткын немецлар арасында безнең танышларыбыз бар иде... Мине төрмә кәнсәләренә чакырдылар да азат ителүем турында әйттеләр. Аннары бер камерага керттеләр, җыештыручы немецлар минем киемнәремне алып килде. Төрмәдән чыккач киемнәремне капшап карасам, анда Муса Җәлилнең куен дәфтәре яшереп куелган иде. Күрәсең, аны әлеге шул киемнәрне китергән немецлар куйган булгандыр. Ә аннары, Франциядә чакта, мин ул дәфтәрне Нигъмәткә бирдем»[210]. Нигъмәт Терегулов[211] аны Франциянең Ле Пюи лагеренда Әмир Үтәшевка[212] тапшыра. Ул 1945 елның 1 сентябрендә совет-герман чигендә

[208] Мостафин Р. Җәлил хатын кем тапкан? / Р. Мостафин // Мәдәни җомга. – 2019. – 8 май.

[209] *Габбас Шәрипов* – Габбас Хәмзә улы Шәрипов (1918–?), сугышта әсирлеккә төшә. 1942 елның декабрендә «Идел-Урал» легионына китерелә. 1943 нең июнендә 827 нче батальон составында Көнбатыш Украинага җибәрелә. Батальондагы яшерен оешмада катнашуда гаепләнеп кулга алына, Львов төрмәсенә китерелә. Аннары Берлинга Моабит төрмәсенә озатыла, М. Җәлил белән очрашалар. Анда ниндидер гаепләре өчен кулга алынган немецлар да була. Дәфтәр алар аша тапшырыла. Озакламый Г. Шәриповны төрмәдән чыгарып, янә легионга кайтаралар. 1944 нең мартында Франциянең Югары Луара департаменты Ле-Пьюи шәһәренә китерелә. Биредә Әмир Үтәшев һәм Нигъмәт Терегулов белән таныша. Франкт-на-Майне шәһәрендә совет хәрби разведкасы Ә. Үтәшевне ватанга хыянәт итүдә гаепләп кулга ала. Ул әйберләре белән бергә М. Җәлилнең дәфтәрен дә Н. Терегуловка биреп өлгерә. Г. Шәрипов сугыш тәмамланып илгә кайткач, кулга алынып, 10 елга сөргенгә җибәрелә. Иреккә чыккач, Волгоград өлкәсе Красноармейский районы Малые Чапурники авылында яши. 1968 дә исән була.

[210] Мостафин Р. Өзелгән җыр эзеннән: әдәби-документаль повесть Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 210–211.

[211] *Нигъмәт Терегулов* – Нигъмәтулла Мөхәррәм улы Терегулов 1911 елның 10 гыйнварында Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзер Башкортстан Республикасы Благовар районы) Каргалы авылында туган. «Волховстрой» төзелешендә эшли, Татарстанның Чаллы якларында яши, Казанда икееллык хокук мәктәбен тәмамлаганнан соң, Саба районында адвокат була. 1941 нең 26 июлендә хәрби хезмәткә алына, Чкалов шәһәрендә алты ай укыганнан соң, 1942 нең 29 гыйнварында лейтенант дәрәҗәсе бирелә, взвод командиры була. 1942 нең 26 августында әсирлеккә төшә, унлап концлагерь аша үтә. «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы була. 1944 нең 6 апрелендә Франциянең Сандитен шәһәрендәге лагерьдан кача. Башкортстанга кайткач, Алкинода тикшереү үтә һәм Уфа шәһәрендә төпләнә. 1946 ның мартында кулга алына һәм Амур өлкәсенә 10 елга сөргенгә җибәрелә. Аның Извисковая станциясеннән 1947 нең 13 апрелендә Уфада яшәүче Мөкәррәмә апасына язган бер хаты сакланып калган. Н. Терегулов 1947 нең август аенда Ургал станциясендә вафат була.

[212] *Әмир Үтәшев* – Әмир Галимҗан улы Үтәшев, антифашист, Бөек Ватан сугышында Франциянең Каршылык хәрәкәтендә катнашучы, 1919 елның 15 сентябрендә Уфа губерна-

кулга алынганда дәфтәрне янә Н. Терегуловка биреп өлгерә. Н. Терегулов аны 1946 елның 29 мартында Казанга алып килә. М. Җәлилнең хатыны Әминә кызы Чулпан белән бу вакытта Мәскәүгә китү сәбәпле, дәфтәрдә язылган адрес буенча А. Алишның хатыны Рокыя Тюльпанованы (?–1993) табып, аңа тапшыра. Р. Тюльпанова исә дәфтәрне Татарстан Язучылар союзына илтеп бирә.

Дәфтәр хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда 122590 номеры белән саклана. Аның 126–128 битләрендә шулай язылган: «Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска. Моны язды татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил. Аның тарихы болай: Ул 1906 елда туган. Гаиләсе[213] Казанда һәм Мәскәүдә. Илдә иң зур шагыйрьләрдән санала. 1942 елны сугышка килде һәм әсир төште. Әсирлектә күп азаплар чигеп, 40 үлемнән калып, ахырында Берлингә китерелде. Берлиндә сәяси яшерен оешмага катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 нең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул! Муса Җәлил. 1943, декабрь. Сәяси гаепләнеп утыручы татар егетләре Гариф Шабаев – Үзбәкстан бухгалтер. Муса Җәлил, шагыйрь – Казан. Әхмәт Симай – Мәскәү, журналист. Габдулла Баттал – Казан. Кормаш Г. – Казан. А. Алиш – язучы, Казан. Булатов Фуад – Казан. Сәйфелмөлеков – Үзбәкстан. Хисаметдинов – Үзбәкстан. Мичурин – юрист, Үзбәкстан. Әмиров – Казан. Шәрипов Габ. Хыянәтче Җәләлетдинов – Үзбәкстан. Болар татар легионын таркатуда, совет фикерен таратуда, күмәк качу оештыруда гаепләнәләр». Соңгы (титул) битендә: «Scaripow. Taschenßwch fur deutsches-Türkisch-rusısch Wort und Gedicht. Şiqerlər həm ləqət».

1947 елның 2 апрелендә М. Җәлилнең латин хәрефләре белән язылган тагын бер шигырьләр блокнотын Татарстан Язучылар союзына тапшыралар. Ул 1943 елның декабреннән 1944 елның мартына кадәр шагыйрь белән бергә Лертерштрассе хәрби

---

сы Бәләбәй өязе (хәзер Башкортстан Республикасының Благовар районы) Каргалы авылында туган. Уфа кооператив техникумын тәмамлагач, ТАССРның Арча районы кулланучылар җәмгыятендә баш хисапчы урынбасары, баш хисапчы булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, хәрби хезмәткә алына, Алабуга шәһәрендә политруклар әзерли торган кыска сроклы курслар үтә. Курск өлкәсендә каты яралынап, аңын югалткан хәлдә 1942 нең 6 июлендә әсирлеккә төшә. Анда «Идел-Урал» легионында немец-фашистларга каршы яшерен көрәш оешмасы әгъзасы була. 1945 нең 1 сентябрендә кулга алына, ләкин аннан котыла. Әмма 1948 нең 21 июлендә кабат кулга алына һәм Идел буе хәрби трибуналы аны «Ватанга хыянәт итүдә» гаепләп, 25 елга сөргенгә хөкем итә. 1955 тә иреккә чыгарыла, 1962 дә аклана. 1996 ның 6 февралендә Казанда вафат була.

[213] «Квартиры» дигән сүзгә алыштырылган: Җәлил М. Моабит дәфтәрләре: төзәт. 2 нче факсимиль басма / Төз. Р. Рахман; текст. гарәп һәм латин график. күч. И. Мөстәкыймов; кереш сүз авт. Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Б. 78.

төрмәсендә утырган бельгияле Андре Тиммерманс (Timmermans, 1917–1978) тарафыннан сакланып кала. М. Җәлил аны Дрезденга мәхкәмәгә алып кителер алдыннан аңа биреп калдыра. А. Тиммерманс блокнотны әйберләре белән бергә өенә посылка итеп сала[214]. Сугыш тәмамаланып үз иленә кайткач, аның үтенече буенча бер танышы блокнотны Брюссель шәһәрендәге СССР консуллыгына илтеп тапшыра.

Дәфтәр хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда 122589 номеры белән саклана. Аның алгы тышлыгының эчке ягына шулай язылган: «Жена Сейфуллина Нина Константиновна (Амине). Г. Москва, Столешников пер. д. 11, кв. 1. Bu təptə – 33 şiƣer. Əsirlektə həm totqьnlьqta – 1942-IX–1943-XI arasьnda jazƣannarьm – 125 şiƣer həm poema. Ləkin qaja jazьjm? Yzem belən bergə yləlr. M. Çəlil». Титул биттәге язулар: «Джалиль М. Musa Çəlil. An meinem liebe Freund Andre Timmermanes von Mussa Jä1il. 1943–44. Berlin». Дәфтәрнең 98 нче битендә шулай язылган: «Musa Çəlil. Муса Джалиль из Москвы. Осужденный к смерти за политику в тюрьме г. Берлин». Арткы тышлыкның эчке ягында шундый мәгълүмат китерелә: «Муса Джалиль. Москва, 25, Столешников пер. д. 11, кв. 1 или Москва, ул. Воровского, 52, Союз писателей. Казань, ул. Баумана, Дом печати. Союз писателей. Муса Джалиль – известный татарский поэт, заключенный  и осужденный к смерти за политику в Германии. Тюрьма. М. Джалиль».

Фашистлар әсирлегендә М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән бергә булган Явдәт (Җәүдәт) Шамбазов (1913–?) исемле кешенең Мусаның исән булуы һәм аның хәзерге вакытта яшерен рәвештә Көнбатыш Германиядә яки ниндидер башка бер илдә яшәве турындагы күрсәтмәсе нигезендә СССР Дәүләт хәвефсезлеге министралыгының 4 нче бүлеге 1946 елның 18 ноябрендә М. Җәлилгә карата эзләп табу эше кузгата. Шул вакытларда ул сатлыкҗан дип игълан ителә. Аның исеме барлык җирләрдән, шул исәптән мәктәп дәреслекләреннән сызып ташлана, гаиләсенә карата тискәре, ягъни хакәрәтле мөнәсәбәт урнаштырыла.

ТАССР Дәүләт хәвефсезлеге министры генерал-майор Дмитрий Токарев[215] М. Җәлил мәсьәләсен күтәреп, 1948 елның 8 маенда Мәскәүгә хат юллый. 7 сентябрьдә СССР Дәүләт хәвефсезлеге министрлыгының Германиядәге вәкиле мәгълүматына нигезләнеп, Казанга «Җәлилов 1945 елда Германянең Көнбатыш зонасына чыккан» дигән хәбәр ирештерелә.

1952 елның 23 июнендә ТАССР Дәүләт хәвефсезлеге комитетының 4 нче бүлеге башлыгы подполковник Качалов, партия Өлкә Комитетының үтенече буенча, Мәскәүдән «М. М. Залиловның һәлак булуын ачыклау»ны сорый. Бер айдан соң СССР Дәүләт хәвефсезлеге министрлыгының 4 нче идарәсе, М. Җәлилнең 1944 елда һәлак булуы сәбәпле, аны оператив эзләү эшен туктатылуы турында Казанга рәсми рәвештә хәбәр итә.

---

[214] Бу хакта тулырак: Симонов К. Бер камерада / К. Симонов // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 218–219.

[215] *Дмитрий Токарев* – Дмитрий Степанович Токраев (1902–1993), генерал-майор, 1948–1953 елларда ТАССР дәүләт иминлеге министры; М. Җәлилнең якташы.

Д. С. Токарев ВКП(б) Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре З. И. Моратовка[216] 1952 елның 2 августында М. Җәлилнең гаепсезлеге турында белешмә тапшыра[217].

1953 елның апрель аенда Татарстан Язучылары союзының Г. Тукай исемендәге клубында «Моабит дәфтәрләре» белән танышу кичәсе үткәрелә. Г. Кашшаф «Совет Татарстаны» газетасында М. Җәлил һәм аның тоткынлыкта язган әсәрләре турында күләмле мәкалә бастыра. Кульъязмаларның кыскача тарихын тасвирлаганнан соң шулай яза: «Безнең алда шагыйрьнең 112 исемдә шигырьләре ята, аларның бары 17 исемдәгесе кабатланган. 97 оригиналь шигырь Муса Җәлилнең тоткынлыкта узган бөтен тормышын. Нинди уйлар, нинди кичерешшләр белән яшәгәнлеген күз алдына бастыра алалар»[218]. Шунда ук шагыйрьнең «Кичер, илем!», «Җырларым», «Ышанма», «Корыч», «Яңа ел теләкләре», «Кошчык» дигән шигырьләре беренче тапкыр укучы игътибарына тәкъдим ителә.

«Литературная газета»ның 1953 елгы 25 апрель санында «Стихи, написанные в Моабите» дигән баш астында М. Җәлил турында кыскача мәкалә белән аның рус теленә тәрҗемә ителгән алты шигыре бастырыла[219].

Ул шул ук елда Г. Кашшаф «Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр» исеме белән М. Җәлилнең җыентыгын «Үлемсезлек (Муса Җәлилнең соңгы шигырьләре)» дигән мәкалә һәм искәрмәләр белән тулыландырып бастырып чыгара[220]. Басмада шагыйрьнең илгә кайтып ирешкән ике дәфтәре нигезендә төзелгән һәм 94 шигыре тупланган.

Г. Кашшаф, әйтергә кирәк, М. Җәлилне аклауга зур өлеш керткән язучы һәм галимнәрнең берсе. Әмма бу уңай белән бер сәер күренеш тә ачыклана. Чөнки «ФСБ архивларында гражданин Миргази Солтан улы Кашаповтан сорау алу беркетмәләре бар, анда бердәнбер сорау мондый: «Блокнотыгызга бу язманы кайчан, нинди шартларда теркәдегез?». Эш шунда ки, Миргази Солтан улы, легион һәм комитетка катнашы булган кешеләрне кайчагында чекистлардан алданрак эзләп табып, аларның истәлекләрен язып алган һәм һәр кәгазь битенә имзаларын куйдырган. Әлеге параллель тикшерү чекистларга мәгълүм булгач, алар Кашшафны төннәрен алып китә, яный башлаган, әмма иректә калдырганнар»[221].

Октябрь аенда Татарстан Язучылары союзы каршында М. Җәлилнең әдәби мирасын җыю һәм өйрәнү буенча махсус комиссия төзелә.

---

[216] *З. И. Моратов* – Зиннәт Ибәт улы Моратов (1905–1988), партия һәм дәүләт эшлеклесе.

[217] Муса Җәлил – документларда... – Б. 533–538.

[218] Кашшаф Г. Корыч ихтыярлы шагыйрь (Муса Җәлилнең соңгы шигырьләре турында) / Г. Кашшаф // Совет Татарстаны. – 1953. – 30 апр.

[219] Стихи, написанные в Моабите // Лит. газ. – 1953. – 25 апр.

[220] Җәлил М. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр / Г. Кашшаф ред. / М. Җәлил. – Казан: Таткнигоиздат, 1953. – 206 б.

[221] Кашапов Р. Җәлилчеләр батырлыгы бизәүгә мохтаҗ түгел / Р. Кашапов // Мәдәни җомга. – 2018. – 24 авг.

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре З. И. Моратов М. Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирүне юллап һәм шагыйрьнең тууына 50 ел тулу юбилеен 1956 елның февралендә үткәрергә рөхсәт сорап КПСС Үзәк Комитетына 1955 елның 19 ноябрендә мөрәҗәгать итә[222].

1956 елның 30 гыйнварында СССР Верховный Советы Президиумының «Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларга каршы сугышларда тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткән өчен, үлгәннән соң, шагыйрь Муса Җәлилгә (Муса Мостафа улы Җәлиловка) Советлар Союзы Герое исеме бирелә» дигән Указ проекты КПСС Үзәк Комитетының Президиумы тарафыннан раслый. СССР Верховный Советы Президиумының 1956 ел, 2 февраль Указы белән Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларга каршы сугышларда тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткән өчен, үлгәннән соң, шагыйрь Муса Җәлилгә (Муса Мостафа улы Җәлиловка) Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Бу уңай белән Казанда 3 февральдә Офицерлар йортының Колонналы залында киң җәмәгатьчелек катнашында тантаналы митинг була. Анда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре З. И. Моратов (1905–1988), ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре В. В. Горбунов, шагыйрь Гали Хуҗиев (1912–1966), майор И. П. Мочалов (?–?), язучылар Гомәр Бәширов (1901–1999), Кави Нәҗми (1901–1957), Шәйхи Маннур (1905–1980), композитор Нәҗип Җиһанов (1911–1988), инженер И. М. Гафуров, эшчеләр М. Ф. Мамакин, М. Җиһаншина чыгыш ясый[223]. Шул көннәрдә матбугатта Г. Кашшафның татар һәм рус телләрендә «Патриот-шагыйрь»[224], «Бессмертие»[225], Михаил Луконинннның (1918–1976) «Сын народа Муса Джалиль»[226] дигән мәкаләләре басыла.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премиясе буенча СССР Министрлар Советы каршындагы комитетның 1957 елгы карары буенча «Моабит дәфтәрләре» дигән шигырьләр циклы өчен М. Җәлил Ленин премиясенә лаек була.

Төркия гражданины Казыйм Миршанга[227] 1944 елның август ахыры – сентябрь башында Плётцензее төрмәсе складыннан унбер кәгазь төргәге бирелә. Араларында М. Җәлилнең дә дәфтәре була. Ул аларны 1946 елның гыйнвар аенда Италиядәге совет илчелегенә тапшыра. Илчелек исә – Мәскәүгә озата. Ләкин ул НКВД органнарында юкка чыга.

[222] Муса Җәлил – документларда... – Б. 539–540.

[223] Көрәшкә, җиңүгә чакыручы тормыш: Шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирүгә багышланган митинг // Совет Татарстаны. – 1956. – 8 февр.

[224] Кашшаф Г. Патриот-шагыйрь / Г. Кашшаф // Совет Татарстаны. – 1956. – 3 февр.

[225] Кашшаф Г. Бессмертие / Г. Кашшаф // Сов. Татария. – 1956. – 14 февр.

[226] Луконин М. Сын народа Муса Джалиль / М. Луконин // Лит. газ. – 1956. – 4 февр.

[227] Казыйм (Касыйм) Миршан, төзүче-инженер, тарихчы-язучы, 1919 елның 4 июлендә Кытайның (Көнчыгыш Төркестанның) Голҗа шәһәрендә туган. 1940 та Истанбулда Босфор урта мәктәбен тәмамлый. Истанбул техник университетының өченче курсында укыганда 1942 дә Германиягә китә. 1946 да Төркиягә кайта һәм 2016 нең 18 июлендә Бодрум шәһәрендә вафат була.

М. Җәлилнең әсирлектәге иҗаты алда карап үтелгән ике блокнот белән генә чикләнми, әлбәттә. Польшаның Радом лагеренда аның белән бергә Башкортстаннан Тәлгат Гыйммранов[228] дигән кеше дә була. Шул вакытта ул маргарин төрә торган пергаменттан кулдан ясалган блокнотка егермеләп шигырь язып ала. Сугыштан соң аларны М. Җәлилнеке дип игълан итә һәм Стәрлетамак шәһәр газетасы редакциясенә китереп тапшыра[229]. Бу яңалык белән язучы Юрий Корольков (1906–1981) кызыксына, Стәрлетамакка барып Т. Гыймранов белән очраша һәм блокнотны үзе белән алып китә, «Литературная газета»да мәкалә һәм рус теленә тәрҗемәдә җиде шигырь, блокнотның фотосурәтен бастыра[230]. Блокноттагы «Безнең батыр» дигән шигырь Абдулла Гафуров исемле кеше тарафыннан «Ил батыры» буларак күчерелгән һәм соңгы строфаларда аерымлык күзәтелә[231]. Ләкин Р. Мостафин тикшеренүләреннән күренгәнчә, Т. Гыймранов блокнотындагы шигырьләрнең авторлык мәсьәләсе ачык кала[232]. Галим үзенең соңгырак тикшеренүләрендә, дөрестән дә, күпчелек шигырьләрнең авторы А. Алиш булуын раслый[233].

1956 елда Г. Кашшаф та Т. Гыймранов белән очрашып сөйләшә. Бу хакта ул шулай яза: «Узган ел мин Гыймранов белән очрашканда, аның сүзләрен язып алдым. Бернәрсә мине гаҗәпләндергән иде. Гыймрановның Муса Җәлил дип ышанган кешесе икенче бер кешегә охшый, без белгән Мусаның кыяфәте, кыланышлары күз алдына килеп басмый иде. Гыймранов, мәсәлән, Мусаның татар легионы киемендә булуын әйтә. Чынында исә Муса Җәлил бервакытта да ул форманы кимәгән һәм легионер булмаган[234]. Гыймранов Муса Җәлилнең тәмәке тартуын раслый һәм мин

---

[228] *Тәлгат Гыймранов* – Тәлгат Әгъзам улы Гыймранов 1914 елның 9 юлендә Уфа губернасы Стәрлетамак өязе (хәзер Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Морадым авылында туган. 1920 дә этисе хәзерге Кырмыскалы районы Югары Төкен авылына имамхатыйп итеп билгеләнгәч, шунда күченәләр. 1935–1939 да Хәрби-диңгез флотында хезмәт итә. 1937 дә гаилә башлыгы репрессиягә дучар ителә һәм атып үтерелә. Т. Гыймранов 1942 дә Кызыл Армия сафларына шушы ук районның Камышлы авылыннан чакырыла. Чыганакларда бу авылда аның 5–6 ел гына яшәгәнлеге әйтелә. Күрәсең, алар 1930 ларда шунда килеп төпләнгән булганнар. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшә, концлагерьларда була. Әсирлектән совет гаскәрләре коткара. Туган якларына кайтканнан соң Стәрлетамак шәһәрендәге оешмаларда тимер-калай эшләре остасы булып эшли. 1980 елның 12 октябрендә шунда вафат була.

[229] Изморосин А. Как Джалиля «открывали» заново / А. Изморосин // Респ. Татарстан. – 2006. – 14 февр.

[230] Корольков Ю. По следам песен Джалиля / Ю. Корольков // Лит. газ. – 1956. – 3 марта.

[231] Ил батыры // Соц. Татарстан. – 1965. – 22 дек.

[232] Мустафин Р. По следам поэта-героя. Книга-поиск. Изд. втор., перераб. и доп. / Р. Мустафин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. – С. 310.

[233] Мостафин Р. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты / Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 197–201.

[234] Өченче империя мәхкәмәсенең хөкем карарында да ул *легиончы* (Legionär) буларак түгел, ә *язучы* (Schriftsteller) дип күрсәтелгән: Муса Җәлил – документларда... – Б. 527, 528.

аңа портсигар ясап бирдем, – дип сөйли... Мин Муса Җәлилне 1928 елдан бирле беләм, тик бер вакытта да тәмәке тартуын хәтерләмим»[235].

Ничек кенә булмасын, Т. Гыймранов алып кайткан шигырьләр зур әһәмияткә ия, әлбәттә. Киләчәктә алар ныклап тикшерелер, авторы да төгәл ачыкланыр.

М. Җәлил белән әсирлектә бергә булган Гарәф Фәхретдинов[236] шагыйрьнең «Язлар килер», «Үлгән улыңнан хат», «Кайту маршы», «Таң маршы», «Азатлык маршы», «Таң», «Соңгы сүз» дигән шигырьләрен сугыштан соң «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә китереп тапшыра һәм алар басылып чыга[237]. Бу әсәрләр һәм Г. Фәхретдинов турында Г. Кашшаф кызыклы мәкалә бастыра[238]. Г. Фәхретдиновның матбугатта басылган язмасы да гыйбрәтле[239].

Двинск шәһәрендәге лагерьда М. Җәлил үзе белән бергә булган Гариф Хафизовка (?–?) блокнотын биреп, исән кайта алса, аны Казанга яки Уфага редакциягә тапшыруын үтенә. Анда «Гариф дуска» дигән шигырен дә яза. Ләкин, кызганыч ки, әсирләрне мунчага китергәч, тикшерүче немец офицеры блокнотны кулыннан тартып ала һәм янып торган мичкә ташлый[240].

Г. Хафизов исән-сау туган якларына кайта һәм Башкортстанның Сибай шәһәрендә яши. Еллар үткәч, М. Җәлилдән ишеткән ике шигырьне урындагы газета редакциясенә китерә[241].

1930–1931 елларда Мәскәүдә Карл Либкнехт исемендәге педагогия институтында укыган вакытында М. Җәлилне белгән, шулай ук Двинск лагеренда аның белән

---

[235] Кашшаф Г. Шагыйрь эзеннән / Г. Кашшаф // Совет әдәбияты. – 1957. – № 5. – Б. 97.

[236] *Гарәф Фәхретдинов* – Гарәф Кәшшафетдин улы Фәхретдинов 1920 елда ТАССРның Бөгелмә кантоны (хәзер Татарстан Республикасы Бөгелмә районы) Карабаш авылында туган. 1935 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый. 1936 елда гаиләләре Урта Азиягә (Бохарага) күченеп китә. 1940 та Кызыл Армия сафларына чакырыла. Бөек Ватан сугышында Киев өчен барган сугышларда каты яраланып, әсирлеккә эләгә. Уннарча концлагерьларда (Борисполь, Дарница һ. б.) була, сигез тапкыр кача. М. Җәлил (ул вакытта аны Гумеров буларак белә) белән 1942 нең ахырында Демблин лагеренда очраша. 1943 нең язында Радом лагерена китерелә. Анда яшерен оешма төзегән культвзводта Дим Алишев исеме белән җырчы буларак катнаша. Соңгы тапкыр Франциядәге Ле Пию лагереннан кача (1944 елның июнь төнендә) һәм француз партизаннары белән Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә фашистларга каршы көрәшеп йөри. Илгә кайткач, Алкино лагеренда тикшерүләр үткәннән соң, Баку тарафларына җибәрелә. 1947 елның июль аенда гына Урта Азиягә кайта. Ул бары тик 1989 елның 29 июнендә генә тулысынча аклана. 2002 елда Ташкентта вафат була.

[237] Муса Җәлилнең яңа табылган шгырьләре // Совет әдәбияты. – 1957. – № 5. – Б. 4–7.

[238] Кашшаф Г. Шагыйрь эзеннән... – Б. 96–108.

[239] Фәхретдинов Г. Кайда минем Илем?!.. / Г. Фәхретдинов // Казан утлары. – 1994. – № 8. – Б. 136–150; – № 9. – Б. 147–162.

[240] Хафизов Г. Блокнот утта янды / Г. Хафизов // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 125–127.

[241] Симонов В. Блокнот, найденный в Стерлитамаке / В. Симонов // Сов. Башкирия. – 1966. – 15 февр.

кабат очрашкан Салих Ганиев (?–?) ул блокнотны күрүен, анда шигырьләр язылган булуын раслый[242].

Вустрау лагеренда М. Җәлил белән бергә булган Зиннур Мөхәммәдиев (?–?) аның әсирләргә немец телен өйрәнергә дип бирелгән кәгазьләрдән дәфтәр эшләп, шигырьләр язуын искә ала. Әмма тимер мичкә яшерелгән ул дәфтәр бер тентү вакытында табып алына һәм яндырыла[243].

Берлинда «Идел-Урал» комитеты тарафыннан татар телендә нәшер ителүче «Татар әдәбияты» журналының мөхәррире Әнвәр Галим[244] М. Җәлилнең «Муса», «Матурлык», «Мактанчык», «Маза», «Маҗара», «Михнәт», «Миһербансызлык», «Могҗиза», «Мохит», «Моңдаш», «Мөсафир», «Мөртәт», «Монафикъ» исемле шигырьләре булганын һәм аларны латин хәрефләрендә язу машинасында басмага әзерләвен искә ала[245].

Бөек Ватан сугышында катнашкан Гобәйдулла Салихов[246] әсирлектә Польшадагы Седльце лагеренда 1942 елның октябрендә М. Җәлил белән очраша. Ул аның

---

[242] Ганиев С. «Эчтән шартлатырга…»... – Б. 130.

[243] Мөхәммәдиев З. Вустрау / З. Мөхәммәдиев // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 140.

[244] *Әнвәр Галим* – Әнвәр Айдагулов (?–1988), Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшә. 1943–1945 елларда «Идел-Урал» комитетында Ш. Алмасның ярдәмчесе була. «Татар әдәбияты» журналының мөхәррире вазифасын башкара. Сугыштан соң Мюнһен шәһәрендә нәшер ителгән «Ватан» журналында мөхәррир була. 1948–1951 дә Көнбатыш Германиянең Киль университетында укый. 1953 тән башлап пенсиягә чыкканчы «Азатлык» радиостанциясендә диктор-комментатор булып эшли. 1968 дә Мюнһеннән Америка Кушма Штатларына күчеп яши һәм «Азатлык» радиосының Нью-Йорк бюросында хезмәт итә. 1988 нең 3 мартында шунда вафат була.

[245] Галим Ә. Муса иманлы китте / Ә. Галим // Идел. – 1993. – № 2. – Б. 33.

[246] *Гобәйдулла Салихов* – Гобәйдулла Зарифулла улы Салихов, финанс хезмәткәре, 1914 елның 23 августында Оренбург губернасы Орск өязе 6 нчы Үсәргән волосте (хәзер Оренбург өлкәсе Куандык районы) Бикташ авылында туган. 1921 елдан Башкортстан АССРы Зилаер кантоны Югары Назар авылында әнисе ягыннан абыйсы тәрбиясендә яши. 1928–1931 дә мәктәптә белем ала, колхозга керә (1930). 1932 дә «Сакмар» совхозы каршында оештырылган мал табиблары әзерләү курсында укый. 1934–1935 тә Оренбург өлкәсе Зианчура (1959 дан Куандык) районы Чебатарево сельпосында сатучы булып эшли. 1937 дә ике айлык финанс курсын тәмамлый. Зианчура районы буенча өлкән госстрах инспекторы була. Берникадәр вакыттан соң Бурангол авылының «Кызыл таң» колхозында хисапчы булып эшли. 1938 дә дүрт айлык хәрби әзерлек, Оренбургта бер айлык хәрби курсларда укый. Совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның 30 июнендә Кызыл Армия сафларына алына. Саратов өлкәсе Вольск шәһәрендә хәрби химия училищесында укып кече лейтенант дәрәҗәсе ала һәм взвод командиры итеп тәгаенләнә. 1941 нең 5 июлендә Воронеж шәһәре янындагы камалышта әсирлеккә төшә. Радом, Седльце, Берлин, Венайзин, Линце лагерьларында була. Соңгысыннан 1945 елның 5 маенда Америка гаскәрләре коткара. Төрле фильтрация лагерьларын үтә, кече лейтенант дәрәҗәсе кайтарыла һәм, ниһаять, 1945 нең декабрендә демобилизацияләнә. Чкалов (1957 дән Оренбург) өлкәсе Зиан-

«Дустым хисе», «Дустыма», «Сөйгән дустыма», «Озатып калучы», «Туган ил сулары», «Картлык» исемле алты шигырен латин хәрефләрендә башкорт теленә әйләндереп күчереп ала һәм аларны сугыштан соң югалтусыз алып кайтуга ирешә[247]. М. Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүчеләрнең берсе, әдәбият галиме Хәнәфи Бәдигый (1941–2020) аларны тәфсилле тикшереп, «Кыскача нәтиҗә ясап әйткәндә, Гобәйдулла Салихов тарафыннан күчереп алынган алты шигырьне, дөрстән дә, Муса Җәлил иҗаты – аның «Седльце шигырьләре» дип әйтә алабыз»[248] дигән фикергә килә.

Журналист, төбәк тарихын өйрәнүче Азат Сөнкишев (1944–2024) бу шигырьләрне А. Алишка нисбәт итә һәм М. Җәлилнең 1942 елда Седльцеда булмавын үзенең аргументарының берсе итеп китерә[249]. Ләкин «Гали Корбанов (ул анда Мичурин фамилиясе белән йөргән) Мусаның Орша шәһәрендәге пересыльный төрмә аша Седльце лагерена, аннан Вустрауга күчерелүе турында сөйли»[250].

Моабит төрмәсендә тоткынлыкта булган Михаил Иконников (1920–1989) 1944 елның июль ае ахырларында М. Җәлил аңа биргән блокнот турында шулай хәбәр итә: «Камерада үзем генә чакта Муса Җәлил шигырьләре язылган дәфтәрне алып карыйм, әмма укый алмый идем. Бу бик кечкенә, 9х7 зурлыгындагы, соры һәм сары төстәге, әйбер төрә торган кәгазьләрдән тегелгән, соры катыргы тышлы блокнот иде. Блокнот битләрендә гарәп хәрефләре белән язылган сүзләр тезелгән иде. Барлыгы утыз биткә якын иде, мөгаен анда кырыкка якын шигырь булгандыр...»[251]. Әсирлектән котылгач, 1945 елның 15 маенда фильтрация пунктында тикшерүче ниндидер майор аны ала һәм Совет Язучылары союзына җибәрергә вәгъдә итә. Ләкин ул блокнот юкка чыга.

Әсирлектә ашерен оешма әгъзаларының берсе булган Гали Корбанов (Мичурин) (?–?) язучы Г. Кашшафка сөйләгәннән аңлашылганча, Сабитов фамилияле кешедә М. Җәлилнең ике блокноты сакланган. Ләкин ул Франциядә һәлак булган[252].

Имам Нигъмәтҗановның куен дәфтәрендә «Көрәшү» дигән шигырь бар һәм ул теле-стиле ягыннан А. Алишка нисбәт ителә[253]. «Беренче көрәшү (Зиннәткә)» исеме

---

чура районында колхозларда, төрле оешмаларда хисапчы булып эшли. 1973 нең 30 маенда Куандык шәһәрендә юл һәлакәтендә вафат була.

[247] Кәшфиева Л. Муса Җәлил белән бергә... әсирлектә / Л. Кәшфиева // Кызыл таң. – 2015. – 7 май; Нуруллин Р. Акка кара төшсә, югалмый... (Муса Җәлилнең яңа шигырьләре табылу тарихы) / Р. Нуруллин // Безнең мирас. – 2015. – № 8. – Б. 56–61; Бәдигый Х. «Седльце шигырьләре» эзеннән... / Х. Бәдигый // Безнең мирас. – 2015. – № 12. – Б. 92–95; Бәдигый Х. Муса Җәлилнең «Седльце шигырьләре» / Х. Бәдигый // Безнең мирас. – 2015. – № 10. – Б. 71–75.

[248] Бәдигый Х. «Седльце шигырьләре» эзеннән... – Б. 95.

[249] Сөнкишев А. Җәлилнекеме соң алар? / А. Сөнкишев // Безнең мирас. – 2016. – № 1. – Б. 78–80.

[250] Кашшаф Г. Муса Җәлил... – Б. 300.

[251] Иконников М. Фашист тоткынлыгында / М. Иконников // Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәрт. Г. Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 259.

[252] Кашшаф Г. Муса Җәлил... – Б. 398.

белән аталган шул ук шигырьне Төркиядә яшәүче Саидә Арсланбәк 2006 елда әдәбият галиме Р. Мостафинга җибәрә. Ул 1942–1945 елларда Германиядә булган һәм шагыйрь белән ике тапкыр очрашкан бер кешедә сакланган булган икән. Бер үк автор тарафыннан матбугатта бу яңа табыш сыйфатында М. Җәлилнең моңарчы билгеле булмаган шигыре буларак игълан ителә[254].

Әсирлектә М. Җәлил, А. Алиш, Р. Саттардан башка Г. Кормашов, Ә. Симаев, А. Баттал, янә исемнәре әлегә билгесез кала килгән кешеләр дә иҗат иткән. Шигырьләр кәгазьгә дә төшерелгән, ятланып, телдән-телгә дә сөйләнелгән. Халык авыз иҗаты әсәрләре шулай ук хәтердә сакланган. Шуңа күрә авторлар мәсьәләсендә кайбер буталчыклар булуы, текстларда аерым үзгәрешләр күзәтелүе табигый күренеш. Бу хакта Р. Мостафин хезмәтләрендә җентекле аңлатылган[255]. Киләчәктә тагын да табышлар булуы ихтималын истә тотып, әлеге юнәлештә махсус тикшеренүләр үткәрелү сорала.

Мәгълүм чыганаклардан гына күренгәнчә дә М. Җәлилнең ун блокноты булганлыгы ачыклана. Шуларның икесе генә илгә кайтып ирешә. Берсе әсирлеккә төшкәндә, бишесе исә лагерьларда юкка чыга. Ә зур газаплар, гомерне куркыныч астына куеп коткарылган «Ике дәфтәрнең илгә кайтып рәсми органнарга тапшырылгач югалуын аңлатуы да шактый кыен»[256].

Шагыйрьнең әсәрләре авар, албан, әзәрбәйҗан, әрмән, балкар, башкорт, белорус, венгр, вьетнам, гарәп, гөрҗә (грузин), инглиз, испан, итальян, казакъ, калмык, каракалпак, корея, кыргыз, кытай, латыш, ләзги (лезгин), литва, мари, молдаван, мордва, немец, румын, рус, таҗик, төрек, төрекмән, тыва, удмурт, украин, үзбәк, чех, чуаш, эстон, якут һәм башка, гомумән, дөньядагы 60 тан артык телгә тәрҗемә ителгән! Бу хакта чит илләрдәге көндәлек матбугат битләрендә бик күп мәкаләләр басыла[257].

М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты өйрәнүнең төрле аспектлары һәм концептуаль проблемалары **татар телендә** Ә. Исхакның (1905–1991) «Герой-шагыйрь Муса Җәлил (Тормышы һәм иҗаты турында)» (1956); Н. Г. Юзиевның (1931–1996) «Герой-шагыйрь Муса Җәлил (Тормышы һәм иҗат юлы)» (1956), «Муса Җәлил поэмалары» (1960); Г. Кашшафның «Муса Җәлил: Тормышы һәм иҗат юлы турында очерк» (1957), «Муса Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк» (1961); Р. Ә. Мостафинның «Муса Җәлил эзләре буйлап» (1968), «Җәлилчеләр» (1988), «Өзелгән җыр эзеннән: Әдәби-документаль повесть» (2011); Х. М. Җә-

---

[253] Мостафин Р. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты / Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 215–216.

[254] Мостафин Р. «Бер матур җыр булып яңгырасын...» (Муса Җәлилнең яңа табылган шигыре) / Р. Мостафин // Татарстан яшьләре. – 2006. – 5 гыйнв.

[255] Мостафин Р. Җәлилчеләр... – Б. 251–260.

[256] Гыймазова В. Исеме халык телендә / В. Гыймазова, Р. Идрисов // тулпар. – 2006. – № 1. – Б. 7.

[257] Кәримуллин Ә. Планетада канат кагына / Ә. Кәримуллин // Соц. Татарстан. – 1966. – 13 февр.; Аныкы ук. Шундый «диңгез» бар... / Ә. Кәримуллин // Соц. Татарстан. – 1981. – 15 февр.

лилованың «Абыем турында» (1973); Ф. И. Мостафинның «Муса Җәлил – педагог» (1974); М. Максудның (1900–1962) «Сагынган минутларда: Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар» (1977); М. Ш. Маннурованың (1939–2020) «Батырлар җыры. Очерклар» (1980); Ш. Х. Хамматовның (1919–1988) «Муса Җәлил – партия солдаты» (1982), «Муса Җәлил, аның каләмдәшләре» (1986); Х. Г. Бәдигыйның «Дала бөркете: Гасыр белән гасыр арасында. Җанга газиз җирләр» (2016), «Муса Җәлил поэтикасы: әдәби-гыйльми, фәнни-публицистик хезмәтләр» (2019); Х. Ф. Басыйров (1939–2021) һәм А. Х. Басыйровның «Ватанга тугры калдылар: документаль повесть» (2010); Ш. С. Мостафинның (1948–) «Алар – Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан!» (2017); **башкорт телендә** Р. Г. Бикмөхәммәтнең (1928–1995) «Муса Йәлил (Дошманды еңгән йырҙар тураһында)» (1961); **рус телендә** Г. Кашшафның «Поэт-патриот Муса Джалиль» (1955); «Поиск продолжается (О подвиге поэта-героя Мусы Джалиля)» (1965) (Р. Мостафин белән автордашлыкта), «По завещанию Мусы Джалиля» (1984); Ә. Исхакның «Поэт-герой Муса Джалиль» (1956); Р. Бикмөхәммәтовның «Муса Джалиль: Критико-биографический очерк» (1957), «Муса Джалиль: Очерк творчества» (1962), «Муса Джалиль» (1966), «Муса Джалиль: Личность. Творчество. Жизнь» (1989); К. Р. Җаманаклының (1905–1965) «Муса Джалиль – лауреат Ленинской премии» (1958); Юр. Корольковның (1906–1981) «Жизнь – песня: Жизнь и борьба поэта Мусы Джалиля» (1959); «Через сорок смертей: Документальная повесть» (1966); «Не пропавший без вести…» (1971); К. А. Барскаяның «Муса Джалиль» (1968); В. Г. Альтовның (1923–2005) «Юность Мусы Джалиля: Очерк» (1969); Р. Мостафинның «Поэзия мужества (к 60-летию со дня рождения Мусы Джалиля)» (1966), «По следам поэта-героя: Книга-поиск» (1971, втор. перераб. и доп. изд. 1973), «По следам оборванной песни» (1974, втор. изд. 2004; 2021), «Красная ромашка: Рассказы о поэте-герое М. Джалиле» (1981, 1988); «Муса Джалиль: Жизнь и творчество (Довоенный период)» (1986), «Жизнь как песня: Страницы жизни поэта-героя М. Джалиля» (1987); В. Г. Воздвиженскийның (1928–2009) «Моабитские тетради» Мусы Джалиля (О творческом пути поэта)» (1969), «Поэзия Мусы Джалиля» (1981); Х. Җәлилованың «О моем брате: Воспоминания» (1969, 1976); И. Х. Зәбировның (?–?) «Рядом с Джалилем: Документальный очерк» (1977), «Джалиль и джалильцы: Документальные очерки и этюды» (1983, втор. изд. 1990); Й. Н. Исәнбәтнең (1936–2021) «Муса Джалиль и татарская музыка» (1977); Ә. Г. Мәхмүдовның (1947–2018) «Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля» (1980), «Лишь в свободе жизни красоты…». Поэтическое наследие Мусы Джалиля в свете современной эстетической мысли» (2006); Ш. Х. Хамматовның «Муса Джалиль – солдат партии» (1984), «Муса Джалиль – интернационалист» (1988); Ф. И. Мостафинның «Муса Джалиль – педагог» (1986); Ф. Урманчиевның «Волшебный клубок: Муса Джалиль и народное творчество» (1995); А. Г. Әхтәмҗанның (1930–2018) «Муса Джалиль и его соратники в Сопротивлении фашизму» (2006, втор. доп. изд. 2015); К. С. Садыйковның «Сибиряк – сподвижник Мусы Джалиля = Муса Җәлил көрәштәше – себер егете: воспоминания о Салиме Аникине: сборник публицистических очерков, архивных документов, воспоминаний» (2013) дигән хезмәтләрендә ачык чагылыш таба.

Филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсе алу өчен Р. Г. Бикмөхәммәтов «Творческий путь Мусы Джалиля» (1955); Н. Г. Юзеев «Поэмы Мусы Джалиля» (1958); М. С. Кашафетдинов (Гази Кашшаф). «Основные этапы развития татарской советской литературы и творчество Мусы Джалиля» (1960); В. Г. Воздвиженский «Моабитские тетради» М. Джалиля и их место в советской литературе военных лет» (1968); Р. Ә. Мостафин «Моабитский период жизни и творчества Мусы Джалиля в свете новых материалов и изысканий последних лет» (1971); И. Х. Зәбиров «Муса Джалиль и моабитская группа татарских поэтов» (1971); Ә. Г. Мәхмүтов «Идейно-эстетическое своеобразие творчества Муса Джалиля (к вопросу об эстетическом идеале) (1980); К. Г. Бәдыйков «Поэтико-стилевые тональности и их словесное выражение в произведениях М. Джалиля (Период Великой Отечественной войны)» (1982); С. С. Арсланова «Лексико-семантические, стилистические особенности и поэтическая ономастика либретто Мусы Джалиля «Алтынчэч» и «Ильдар» (2004); Н. Д. Тилекова «Научно-методические основы изучения восточной литературы в VII классе кыргызской школы (Муса Джалиль, Расул Гамзатов, Назым Хикмет)» (2016); сәнгать фәннәре гыйльми дәрәҗәсе алу өчен Й. Н. Исәнбәт «Муса Джалиль и татарская музыка» (1970); педагогоия фәннәре гыйльми дәрәҗәсе алу өчен Ф. И. Мостафин «Общественно-политическая деятельность и педагогические идеи Мусы Джалиля» (1972) дигән темага диссертация яклый.

М. Җәлилгә багышлап үткәрелгән гыйльми чаралар шулай ук шагыйрьне өйрәнүнең әһәмиятле бер тармагы булып тора. Шундыйлардан, мәсәлән, «Муса Джалиль: материалы Всесоюзная научная конференция, посвященная 70-летию со дня рождения Поэта-героя» (1978); «Муса Джалиль и патриотическое традиции в советской литературе: материалы Всесоюзная научная конференция, посвященная 80-летию поэта-героя» (1989); «Җәлилиана үсештә: Герой-шагыйрь, Ленин премиясе лауреаты, атаклы «Моабит дәфтәре» авторы Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган Вузара гыйльми-гамәли конференция материаллары (17 март 2006 ел) (2006); «Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века» (2006); «Умирая, не умрёт герой…». Муса Джалиль и современность: материалы межвузовской научно-практической конференции «Джалилевские чтения», г. Екатеринбург, 10 марта 2006 г.» (2006) һәм башка фәнни конференцияләрне билгеләп үтәргә мөмкин.

Шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә өйрәнү өчен төрле методик әсбаплар, уку ярдәмлекләре төзелә. Мәсәлән, шундыйлардан Г. Ф. Саттаровның (1932–2020) «М. Җәлил шигырьләренең художество эшләнешен анализлау: Укытучыларга ярдәмгә: Татар мәктәпләрендә татар теле һәм рус теле укытучыларының өлкә конференциясе материаллары» (1958); А. Әминев һәм Һ. Галиеваның «Муса Җәлил мәктәптә: Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү мәсьәләләренә карата: Укытучылар өчен ярдәмлек» (1967); «Муса Джалиль — поэт и воин: методическая рекомендация к 100-летию со дня рождения» (2005) дигән һәм башкаларны әйтергә мөмкин.

Лекторлар өчен ярдәмлекләрдән Ш. Рахманкуловның (?–?) «Патриот шагыйрь Муса Җәлил» (1954), «Поэт-герой Муса Джалиль» (1956) китапларын күрсәтергә мөмкин.

Герой шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү буенча шактый эшләр башкарыла. Тууына 50 ел тулу уңае белән КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Югары Советы Президиумы Татар дәүләт опера һәм балет театрына М. Җәлил исемен бирә.

1959 елда аның исемендәге почта маркасы басыла, 1961, 1966 елларда аңа багышлап хат конвертлары чыгарыла.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, 1964 елның 25 март указы белән, Әлмәт районының Сөләй авыл Советы территориясендә барлыкка килгән яңа торак пунктны терки һәм аңа «Җәлил поселогы» дигән исем бирелә. Ул Әлмәт шәһәр Советы буйсынуына тапшырыла.

Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылында М. Җәлилнең мемориаль музее (1976), Казан шәһәренең Горький урамындагы 17 нче йортта мемориаль квартира-музее (1983), Минзәлә шәһәренең педагогия училищесы бинасында (1985), Пермь шәһәренең 70 нче мәктәбендә (1971) музее ачыла. Казандагы квартира-музее хакында И. З. Минһаҗеваның «Казанда Муса Җәлил музее» (1985); «Музей Мусы Джалиля в Казани (путеводитель)» (1984); Н. Фәттахованың «Музей-квартира Мусы Джалиля: буклет» (2002, 2006) дигән белешмәлекләре бар.

Элекке СССРдагы бик күп шәһәрләрдә, авылларда урамнарга аның исеме бирелә, совхоз-колхозлар, китапханәләр, әдәби берләшмәләр[258], мәктәпләр[259], җир транспортлары, су һәм һава[260] кораблары, күк җисемнәре, томонимик объектлар һ. б. аның исемен йөртә. Мәсәлән, Казан шәһәренең бер урамына, Мәскәү шәһәренең Кызыл Гвардия районының Орехово-Борисково дигән өлешендә төзелеп килгән яңа урамга (1976), БАМдагы Беркакит поселогының үзәк урамына (1978), Бөек Новгород, Әстерхан, Минзәлә шәһәрләренең бер урамына, Яр Чаллы шәһәренең бер проспектына, Ставрополь крае Минераловодск муниципаль округы Канълы авылындагы бер урамга; Минзәлә районының бер колхозына (1980), Үзбәкстанның Каракалпак АССРы Кегейли районындагы «Куваныш жармагы» («Куаныч елгасы») совхозына[261], Пермь өлкәсенең Көнгер районындагы бер колхозга; СССР Язучылар союзының Чиләбе бүлеге каршында эшләп килүче татар-башкорт әдәби берләшмәсенә (1966); Яр Чаллы шәһәрендәге яңа китапханәгә (1975); Мәскәү шәһәрендәге 1186 санлы этнокультур татар компонентлы гомуми белем бирү мәктәбенә Муса Җәлил исеме; Татарстандагы бер нефть промыселы «Җәлилнефть» дип атала.

1959 елда Казан тимер юлы станциясендә патриот шагыйрь Муса Җәлил исемендәге тепловоз тимер юлчыларга тапшырыла. Советлар Союзы заказы буенча Югославиянең Пула шәһәре «Ульяник» верфендә «Муса Җәлил» исемендәге тепло-

---

[258] Мәсәлән, Чиләбе шәһәрендәге татар-башкорт әдәби түгәрәге 1964 елда берләшмә дәрәҗәсенә күтәрелеп, Муса Җәлил исеме белән, Чиләбе өлкәсе язучылар бүлекчәсендә эшли: Мостафин В. Чиләбе... герой-шагыйрь исемендәге... / В. Мостафин // Кызыл таң. – 1966. – 15 февр.

[259] Мәсәлән: Аляутдинова Д. О татарской школе Москвы / Д. Аляутдинова // Халкым минем. – 2011. – № 7. Сент.

[260] Тукай аэропортында Җәлил очкычы // Мәдәни җомга. – 2020. – 3 июль.

[261] Исхаков З. Имени поэта-героя / З. Исхаков // Сов. Татария. – 1981. – 1 февр.

ход ясалып, 1966 елда беренче рейска чыга, 1968 елда Антарктидагы бер тауга, 1972 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Т. М. Смирнов тарафыннан ачылган 3082 нче кече планетага М. Җәлил, 2020 елда «Аэрофлот» компаниясенең бер самолетына «М. Җәлил» исеме бирелә.

Курск өлкәсе, Рыльск районы «Марьино» санаториясе бинсында (1967), Оренбург шәһәрендә 1926–1927 елларда комсомолның Оренбург губком аппараты урнашкан бинага (1969), Даугава-Двинск шәһәрендә (1975)[262], Казанда Татарабфакта укыган бинага (хәзер Лобачесвкий урамы, 2/31) (1981), Әстерхан шәһәрендә Муса Җәлил исемен йөрткән урамда урнашкан балалар китапханәсе бинасына (1985), Казанның Бауман урамындагы Матбугат йорты диварына (19 нчы йорт) (1986)[263], Мәскәүдә ул яшәгән йортка (Столешников тыкрыгы, 11) (1991), Бөек Новгород шәһәренең М. Җәлил-Духовская урамындагы 26/2 нче йорт диварына (2020), Ставрополь крае Минераловодск муниципаль округы Канълы авылында (М. Җәлил ур., 47 нче йорт) (2023) истәлек такталары куела.

М. Җәлилнең образы әдәбиятта, сәхнә әсәрләрендә, сынлы, рәсем, кино сәнгатендә чагылыш таба. Мәсәлән, Әнвәр Давыдов (1919–1968) «Муса абый» повестен (1964), Шәйхи Маннурның «Муса» романын (1968)[264], мәгариф хезмәткәре Таһир Корбанов[265] «Кызыл чәчәкләр» документаль повестен (1990), драматург Риза Ишморат (1903–1995) «Үлмәс җыр» драмасын (1955), композитор Нәҗип Җиһанов (1911–1988) «Җәлил» (Әхмәт Фәйзи либреттосы) операсын (1959)[266], шагыйрь Ж. Мулдагалиев «Мард шоир қиссаси»н («Герой шагыйрь турында поэма») (1962), язучылар Сәгыйть Агиш «Якташтар» (1963) повестен, Нәкый Исәнбәт (1899–1992) «Муса Җәлил» драмасын (1966), драматурглар Нәҗип Асанбаев (1921–2013) «Ҡанат йәйгәндә» драмасын (1969)[267], Туфан Миңнуллин (1935–2012) «Моңлы бер җыр» драмасын (1981), шагыйрь Хәнәфи Бәдигый «Дала бөркете» (2016)[268] поэмасын, Рафис Корбан «Ватан» (2018) романын иҗат итә.

Үзе исән вакытта утызынчы еллар азагында һәвәскәр сынчы Гыймад Тимербулатов (?–?) тарафыннан беренче бюсты эшләнә. Шулай ук исән чагында сынчы Садри

---

[262] Иванов Е. Мемориаль такта ачылды / Е. Иванов // Соц. Татарстан. – 1975. – 3 авг.

[263] Мемориаль такта ачылды // Совет Татарстаны. – 1986. – 15 февр.; Татарстан яшьләре. – 1986. – 15 февр.

[264] Әсәрнең язылу һәм басылу тарихы турында кара: Исламов Р. «Муса» романының басылмаган өлеше / Р. Исламов // Кызыл таң. – 2015. – 9 сент.; *Аныкы ук*. Баштан соң роман да киселгән (Ш. Маннурның «Муса» романы турында) / Р. Исламов // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2015. – № 3/4. – Б. 239–242.

[265] *Таһир Корбанов* – Таһир Яхъя улы Корбанов (1910–2014), педагог, педагогия фәннәре кандидаты; М. Җәлилнең икетуган энесе.

[266] Бу опера 1960 елда Прага Милли театрында да куела. Тамашада Н. Җиһанов үзе дә була: Пешек Я. «Муса Җәлил» Прагада / Я. Пешек // Азат хатын. – 1961. – № 3. – Б. 20–21.

[267] Курамшин Н. «Канат җәйгәндә» / Н. Курамшин // Соц. Татарстан. – 1970. – 19 май; Гобәйдуллин Х. «Канат җәйгәндә» / Х. Гобәйдуллин, Һ. Мәхмүтов // Соц. Татарстан. – 1970. – 18 июнь; // Акбашев К. Сәхнәлә – Муса Йәлил / К. Аҡбашев // Совет Башҡортостаны. – 1971. – 7 нояб.

[268] Зариф Ф. Җәлил рухын олылау / Ф. Зариф // Мәдәни җомга. – 2016. – 2 дек.

Ахун (1903–1990) эшләгән бердәнбер бронза бюсты хәзерге вакытта Татарстан Республикасының Сәнгать музеенда саклана. Туган авылында (1961), Казан Кремле каршындагы Беренче май мәйданында (1966), Җәлил поселогында (1968), Мәскәү шәһәрендәге 1186 санлы этнокультур татар компонентлы гомуми белем бирү мәктәбе йортында, Оренбург (1996), Санкт-Петербург (2011)[269], Мәскәү (2012), Түбән Кама (2012), Чиләбе (2015) шәһәрләрендә һәйкәле ачыла; Минзәлә шәһәрендә М. Җәлилнең мемориаль музеенда (1960), туган Мостафа авылында (1961), Казанның М. Җәлил исемендәге 26 санлы лицее янында (1967), Минзәлә шәһәренең Ленин комсомолы исемендәге Паркында (1976), (яңартылганы – 2017 дә), Санкт-Петербургта (2011), Тосно шәһәрендә Балалар иҗат йорты каршында (2012), Чиләбе (2015), Түбән Варта (2015), Казакъстанның Усть-Каменогорск (2015) шәһәрләрендә, Казан (Идел буе) федераль уиверситетының йортында (2016)[270], Әстерхан шәһәрендә дәүләт университеты скверында (2017)[271], Свердловск өлкәсененең Серов шәһәрендә Үзәк балалар китапханәсе янында (2022), Якутск шәһәренең «Казанский» скверында (2023), Казакъстан Республикасының Семипалатинск шәһәрендә (2023), Казанда аның исемен йөрткән скверда (2024), Бишкәк шәһәренең 29 санлы мәктәп-гимназиясе территориясендә (2024), Курган шәһәренең Китапханә скверенда (2024), Адыгей Республикасының Кошехабль районы Политотдел хуторында (2025), Санкт-Петербургның М. Җәлил исемендәге 146 нчы урта мәктәбендә (2025)[272] бюсты куела.

Рәссамнар Харис Якупов (1919–2010) «Хөкем алдыннан»[273], Әхмәт Китаев (1925–1996) «Муса Җәлил Моабит төрмәсендә», «Иреккә омтылу», Васил Маликов (1924–1992) «Муса Җәлил», Әмир Вәлиәхмәтов (1927) «Герой шагыйрь Муса Җәлил», Искәндәр Рәфыйков (1929–2018) «Җәлилчеләр», Валерий Скобеев (1938–2022) «Мусаның лирик портреты», Абрек Абызгилдин (1937–2013) «Муса Җәлил һәм Виктор Хара» дигән рәсемнәр яза. Бу исемлекне тагын да тулыландырырга мөмкин.

Яр Чаллы шәһәрендә (1985), Мостафа авылында (2013) М. Җәлил исемендәге мемориаль комплекслар төзелә.

1963 елда ГДР Дефа киностудиясендә Эрих Мильштат (Мюллер) (1904–1970) сценарие буенча «Кызыл ромашка» («Die rote Kamille») дигән фильм төшерелә. М. Җәлил ролендә артист Һильмер Татэ (1931–2016). «Ленфильм» киностудиясе тарафыннан «Моабитская тетрадь» дигән фильм төшерелә (режиссёры Л. А. Квинихидзе (1937–2018), М. Җәлил ролен РСФСРның халык артисты П. Г. Чернов (1917–1988) башкара). Фильм 1968 елда экраннарга чыга[274]. 2024 елда «Кара урман» (сце-

---

[269] Шакирова Э. Санкт-Петербург баеды: шәһәрдә Җәлилгә һәйкәл ачылды / Э. Шакирова // Ватаным Татарстан. – 2011. – 21 май.

[270] Хәмзин Б. Җәлилгә яңа һәйкәл / Б. Хәмзин // Мәдәни җомга. – 2-16. – 21 окт.

[271] Әстерханда Җәлил һәйкәле // Мәдәни җомга. – 2017. – 19 май.

[272] Җәлилгә һәйкәл (Санкт-Петербург) // Мәдәни җомга. – 2025. – 26 сент.

[273] Якупов Х. Хөкем алдыннан / Х. Якупов // Татарстан. – 2006. – № 2. – Б. 47.

[274] О нем подробно см.: Квинихидзе Л. Кровью сердца // Сов. Татария. – 1968. – 7 июля; Чернов П. Вдохновляющий образ / П. Чернов // Сов. Татария. – 1968. – 7 июля; Гринер Б.

нарий авторы һәм режиссеры Р. Кудояров, М. Җәлил ролендә Татарстан Республикасының атказанган артисты З. Закиров) фильмы дөнья күрде һәм шактый гына бәхәсләргә сәбәпче булды[275].

1968 елда Ленин комсомолының 50 еллыгы хөрмәтенә һәм яшь язучыларның, композиторларның, рәссамнарның, актёрларның совет яшьләре турында югары идеяле һәм сәнгати эшләнешле әсәрләре барлыкка китерүдә иҗат активлыкларын тагын да күтәрү максаты белән, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты бюросы Карары белән әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә яшь авторларның югары идеяле һәм сәнгати эшләнешле әсәрләр иҗат иткәне өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге өч премия булдырыла.

1968 елда ТАССР Апас районынның Муса Җәлил исемендәге колхозда ел саен шагыйрьнең туган көнендә өч хезмәт алдынгысына М. Җәлил исемендәге премияләр бирү турында карар чыгара.

СССР журналистлары союзының Оренбург өлкә оешмасы идарәсе Муса Җәлил исемендәге премия булдыра. 1974 елдан башлап ул ел саен матбугат көнендә тапшырыла.

***

М. Җәлил турындагы документларны өйрәнүнең дә үз тарихы бар. Аларны ачыклау, барлау, туплау һәм киң гавам укучы игътибарына тәкъдим итә башлау узган гасырның 60 нчы еллар башына карый.

А. Җәләлов СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивында М. Җәлилнең биографиясенә караган ун документны татар теленә тәрҗемә итеп, «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 4 санында урнаштыра[276].

«Казан утлары» журналының 1965 елгы 5 нче санында «Фронтовиклар хатлары» рубрикасында М. Җәлилнең Татарстан Язучылары союзы рәисе Төхфәт Имаметдиновка (?–?) 1942 елның 25 мартында язган хаты басыла[277].

«Социалистик Татарстан» газетасы 1965 елгы 22 декабрь санында М. Җәлилгә бәйле булган ундүрт документның татар телендә тәрҗемәләре белән үзенең укучысын таныштыра[278].

Әдәбият галиме Р. Р. Гайнанов (1925–1990) «Социалистик Татарстан» газетасының 1966 елгы 13 февраль санында М. Җәлилнең 1927 елның 2 сентябрендә язучы, әдәбиятчы Г. Рәхимгә (1892–1943) «Кечкенә иптәшләр» журналы белән хезмәттәшлек итәргә чакырып язган хатын бастыра[279].

---

Энтузиасты / Б. Гринер // Сов. Татария. – 1968. – 7 июля; Дудко А. С волнением / С. Дудко // Сов. Татария. – 1968. – 7 июля.

[275] Мәсәлән: Хәбетдинова М. «Кара урман» серләре / М. Хәбетдинова // Мәдәни җомга. – 2025. – 19 сент.

[276] Җәлалов А. Муса Җәлил биографиясенә караган яңа документлар / А. Җәлалов // Совет әдәбияты. – 1962. – № 4. – Б. 144–150.

[277] Фронтовиклар хатлары. Муса Җәлил хаты // Казан утлары. – 1965. - № 5. – Б. 42–43.

[278] Герой тормышы – документларда // Соц. Татарстан. – 1965. – 22 дек.

[279] Гайнанов Р. Балалар дусты / Р. Гайнанов // Соц. Татарстан. – 1966. – 13 февр.

Газетаның шул ук елгы 15 февраль санында М. Җәлил, кызы Чулпан, якташы, РСФСРның атказанган һәм Татарстанның халык артисткасы Фатыйма Ильская (1902–1984) 1940 елда төшкән фото беренче тапкыр игълан ителә.

М. Җәлил Орск шәһәрендә азчылык милләт комсомол өяз комитеты инструкторы булып эшләгән вакытта яшәгән квартира хуҗасының кызы Сөмбел Шакир кызы Фәйзуллина (соңыннан фамилиясе – Мөхәммәдъярова, фәнни-тикшеренү институтында инженер-икътисадчы булып эшли) белән төшкән фото турында журналист, язучы Ян Винецкий (1912–1987) «Советская Татария» газетасының 1966 елгы 15 февраль санында кызыклы мәкалә бастыра [280].

Казан дәүләт университетының КПСС тарихы кафедрасы аспиранты В. Скворцов «Казан утлары» журналының 1967 елгы 4 нче санында М. Җәлилнең 1935 елның 1 һәм 7 гыйнварында Кави Нәҗмигә, 50 санлы йортлар идарәсенә, ВКП(б)ның Арча райкомына, Арча район Советына, ВЛКСМның Арча райкомына язган хатларын һәм Татгосиздат управляющие Арслановка хатының факсимилесен укучылар игътибарына тәкъдим итә[281].

